МЕТОДИК ӘСБАП

# ӘДӘБИ УКУ

# 2

Д.М.Абдуллина, Г.Н.Мөхәрләмова



**Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова**

# ӘДӘБИ УКУ

## МЕТОДИК ӘСБАП

## 2

Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән эшләүче укытучылар өчен

**Казан**
**2023**

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)
А13

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият
һәм сәнгать институтында эшләнде

**Абдуллина Д.М.**

А13 Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Методик әсбап : Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән эшләүче укытучылар өчен / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023. — 106 б.

Методик әсбапта 2 нче сыйныфта «Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметы буенча дәреслек белән эшләү тәртибе яктыртыла. Биредә предметны өйрәнүгә куелган максат-бурычлар, планлаштырылган нәтиҗәләр, тематик планлаштыру, дәрес эшкәртмәләре үрнәкләре бирелә.

Әсбап башлангыч сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, 2023
© Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2023
© Абдуллина Д.М., Мөхәрләмова Г.Н., 2023

# ХӨРМӘТЛЕ ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗ!

2 нче сыйныфның «Әдәби уку» дәреслегенә методик ярдәмлек буларак тәкъдим ителгән бу басма әлеге предметны укучыларга җиткерүдәге үзенчәлекләрне аңлатып бирүне күздә тотып эшләнде.

2 нче сыйныф «Әдәби уку» китабы – укучыларга әдәби әсәрнең тормыш чынбарлыгын образлар ярдәмендә сәнгати чагылдыруын кабул итәргә өйрәнүнең беренче баскычы. Моңа ирешү өчен, һәр дәрестә эзлекле һәм максатчан эш алып бару сорала. Иң элек укучы дәреслек белән эшли белергә тиеш. Андагы шартлы билгеләрне тану, кирәкле теманы, әсәрне таба алу беренче шарт булып тора.

2 нче сыйныф укучысы инде укый белә, укыганны һәм тыңлаганны кабул итеп, аңа карата үз фикерен җиткерә ала. Шулай да әле уку күнекмәләрен үстерүгә аерым игътибар таләп ителә. Быел алар сәнгатьле укырга, әсәрнең эчтәлеген ачуда, тавыш, мимика һәм кул хәрәкәтләрен куллануның әһәмиятенә дә төшенә, аны кулланырга да өйрәнәләр.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын 2 сәгать укыту мөмкинлеге булган очракта тәкъдим ителгән темалар икешәр сәгать өйрәнелә. Дәреслектә өстәмә материал бар.

Укучыны сәнгатьле укуга өйрәтүдә берничә кагыйдәне хәтердән чыгармаска кирәк. Укучы өчен үрнәк уку кирәк, бу – укытучы укуы, яки аны алыштырырлык чыганак (аудио, видеоязма). Дәреслек бу таләпләргә җавап бирә: ул мондый чыганак белән тәэмин ителгән. Шулай ук йөгерек укучы сыйныфташының үрнәге дә укучыга яхшы укырга өйрәнү өчен этәргеч була. Текстны сыйныфта чылбырлап уку, рольләргә бүлеп уку һәм сыйныфтан тыш чаралар да укучыны сәнгатьле итеп укырга өйрәтү өчен файдалы. Әлеге эш төрләрен укытучы үзе сайлый. Үрнәк дәресләрдә мондый катгый күрсәтмәләр бирүне кирәк тапмадык.

Сәнгатьле уку баланың әсәрне күңеле аша үткәреп, үзен шул хәлләр эчендә тоеп укуына юл ача. Димәк, ул әсәрдәге вакыйга-

ларны, аның геройларының күңел халәтен, хис-кичерешләрен тулысынча үзе аша үткәрә. Шул ук вакытта аның бу вакыйга, геройларга үз карашлары, бәясе формалаша. Шулар аша ул үзенә тормыш тәҗрибәсе туплый.

2 нче сыйныфта инде укучылар уку гына түгел, әсәрнең (текстның) бөтенлеген, образлылыгын да тоярга өйрәнәләр. Һәр әсәрдә телнең бизәклелегенә дә игътибар юнәлтү сорала. Әсәрләрдән синоним, антонимнарны (предметның база өлешен һәм тирәнтен өйрәнүчеләр өчен дә), сынландыруларны (предметны тирәнтен өйрәнүчеләр өчен генә) күзәтү укучыга әдәбиятның образлар белән эш итүен аңларга ярдәм итә.

Әдәби әсәр белән эшләгәндә, аның жанр үзенчәлеген күрү (чәчмә яки тезмә), *куплет, абзац* төшенчәләренә күнектерү дә сорала.

Димәк, укытучы һәр дәрестә белем һәм тәрбия бирүне, халкыбызның асылына хас әхлак кануннарын җиткерүне максат итә. Бу уңайдан дәреслектә сайлап алынган әсәрләр, аларны өйрәнү барышында бирелә торган сораулар шул максатка яраклаштырылды.

Методик ярдәмлектә бирелгән дәрес үрнәкләре юнәлеш бирү, беркадәр дәреслектәге мәгълүматны укучыга җиткерүнең юлларын күрсәтүне генә күздә тота. Укытучы дәреснең төрен дә, этапларын да укучыларның мөмкинлегеннән чыгып сайлый.

Дәрес әсәрне укып сорауларга җавап бирүне генә күздә тотмый. Ул укучыны сөйләшергә, фикерен белдерергә, аны дәлилләргә, шул ук вакытта башкалар фикерен дә тыңларга, сайлап кабул итәргә өйрәтә. Белем бирүгә куелган таләпләр дә шуны сорый. Дәреслектәге һәр әсәр 2 нче сыйныф укучысын, телне белү дәрәҗәсеннән чыгып, әңгәмәгә тартырга мөмкинлек бирә. Укучының көче җиткән кадәр белем алырга юл ача. Методик әсбапта бирелгән дәрес үрнәкләре укытучыга шул мөмкинлектән файдалану ысулларын күрсәтүне максат итеп эшләнде.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметының төп **максаты** – татар мәдәниятенең мөһим өлеше булган туган (татар) телдәге әдәбиятка сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, укучылар-

ның мәдәни мираска, үз халкының гореф-гадәтләренә тартылуын тәэмин итү, киләчәктә куелган уку бурычыннан чыгып, шулай ук үзләре кызыксынган өлкәгә караган әсәрләрне китапханәләрдән мөстәкыйль рәвештә сайлап алырлык грамоталы укучы формалаштыру.

Максатларны тормышка ашыру түбәндәге бурычларны хәл итә:

- укуга һәм китапка карата кызыксыну тәрбияләү, укучының тормышны күзаллавын формалаштыру;
- укучыларның аралашу (коммуникатив) сәләтен булдыру;
- укучыларның туган (татар) телендә телдән һәм язма диалогик, монологик сөйләмен үстерү;
- кычкырып һәм эчтән (үз-үзеңә) уку техникасын булдыру һәм камилләштерү, текстны төшенү (кабул итү һәм аңлау) алымнарын үстерү, эшчәнлекнең универсаль төрләренә – күзәтүгә, чагыштырма анализга өйрәтү;
- әдәби анализ элементларын куллану аша укучыларны сүз сәнгатенә, туган телдәге әдәбиятка якынайту, аерым әдәби-теоретик төшенчәләр белән таныштыру;
- укучыларның әхлакый һәм эстетик хисләрен формалаштыру, әсәрләрнең рухи асылын аңларга өйрәтү;
- туган (татар) телендә иҗади эшчәнлек сәләтләрен үстерү.

Укыту барышында сыйныфларда белем бирү эчтәлеге түбәндәге эшчәнлек төрләре белән үрелеп бара.

**Тыңлау.** Укытучы һәм сыйныфташлары тарафыннан кычкырып укылган текстны, әңгәмәдәшләренең фикерләрен, үзенә бирелгән сорауларны аңлау. Әйтелгән (ишеткән) сүзнең мәгънәсенә төшенү: фикер алышу аспектын тотып алу, сөйләм эчтәлеге нигезендә сорауларга җавап бирү һәм үз сорауларыңны формалаштыру.

**Кычкырып уку.** Иҗекләп укудан сүз белән укуга күчү, уку тизлеген акрынлап арттыру. Рольләргә бүлеп уку, чылбыр буенча уку барышында кычкырып уку техникасын формалаштыру. Сәнгатьле уку үзенчәлекләрен үзләштерү (башлангыч этапта җөмләләрне тыныш билгеләренә карап, интонацион буыннарга аерып, дөрес итеп, жанр таләпләренә туры китереп уку).

**Үзлегеннән уку (эчтән уку).** Күләме зур булмаган текстны мөстәкыйль уку. Өйрәнелә торган текстта кирәкле мәгълүматларны, аңлашылмаган сүзне сүзлектән табу һәм сайлап уку ярдәмендә төп мәгънәне истә калдыру.

**Сөйләү.** Монологик сөйләм төрләрен үзләштерү: сорауга кыска яисә киңәйтелгән җавап рәвешендә; текстны укудан туган үз тәэсирләрен, тормышны күзәтүләреннән туган тәҗрибәне тапшыру рәвешендә; фикерне текстка таянып дәлилләү рәвешендә (текстта кирәкле урынны табып уку). Диалогик аралашу үзенчәлекләрен үзләштерү: әңгәмәдәшенең әйткәннәрен тыңлый һәм аларга карата үз мөнәсәбәтен белдерә белү (ризалашу / килешмәү). Текст эчтәлегенә таянып, үз фикерләрен дәлилләп яклый белү.

**Язу.** Текст төрләренең аермасын тану (текст-хикәяләү, текст-тасвирлау, текст-фикер йөртү) һәм аларны кечкенә сочинениеләр формасында практик үзләштерү; шәхси күзәтүләр һәм тәэсирләр нигезендә кыска сочинениеләр язу.

**Әдәби әсәр тексты белән эшләү.** Текстның исемен анализлау, сораулар һәм биремнәр системасы аша текстны тикшерү, төп эмоциональ-мәгънәви берәмлекләрне ачыклау (төп фикер, лирик шигырьдә төп кичерешләр, геройларның капма-каршы позицияләре һәм хикәядә автор нәтиҗәсе). Текст төзелешенең үзенчәлекләрен билгеләү, тел-сурәтләү чараларын ачыклау (антонимнар, синонимнар, сынландыру, чагыштыру). Геройның холкын билгели белү (сүз ярдәмендә тудырылган портреты аша, гамәлләрен анализлаудан, сөйләм үзенчәлегеннән чыгып, автор аңлатмалары ярдәмендә), башка геройларның үз-үзләрен тотышына чагыштырма анализ, укытучы ярдәмендә проза әсәрләрендә автор позициясен һәм лирик әсәрләрдә автор кичерешләрен таба белү. Текст белән эшләгәндә, төрле сюжет сызыкларын аерып чыгара белү; эчтәлек ярдәмендә карашлар һәм позицияләрнең төрлелеген күрергә өйрәнү; сюжет үстерелешендә һәм геройларның эш-гамәлләрендә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; автор фикерен аңлау; текстның төп фикерен аерып чыгару; тел-сурәтләү чараларын табу.

**Балалар өчен әсәрләр.** Халык авыз иҗаты әсәрләре. Фольклорның кече жанрлары (санамышлар, табышмаклар, эндәшләр); халык әкиятләре (хайваннар турында әкиятләр, көнкүреш әкиятләре, тылсымлы әкиятләр); мәкальләр һәм әйтемнәр, мәзәкләр. Автор әкиятләре, мәсәлләре, авторларның әдәби әсәрләре. XIX–XX гасырларда туган телдәге (татар) әдәбият классиклары әсәрләре (шигырьләр, хикәяләр). Туган телдәге (татар) балалар әдәбияты классиклары әсәрләре (шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр). Төрле халыклар (Россиянең күпмилләтле дәүләт булуын исәпкә алып) әдәбияты үрнәкләре (хикәяләр, әкиятләр). Балалар өчен вакытлы матбугат басмалары (журналлар).

**Әдәби пропедевтика**. Төрле типтагы рифмалар, халык иҗаты һәм автор әдәбияты әсәрләренең жанр үзенчәлекләрен тану, әдәби әсәрләрдәге тел-сурәтләү чаралары (синонимнар, антонимнар, сынландыру, чагыштырулар, эпитетлар, метафоралар һ.б.) белән танышу һәм аларның кулланылу үзенчәлеген аңлау.

Укучыларның татар халык иҗатының кече жанрлары турындагы белемнәрен системалаштыру һәм «халык авыз иҗаты» төшенчәсен үзләштерү. Әдәби күзаллау алымнарын формалаштыру. Фольклор әсәрләре турында билгеле бер караш булдыру. Фольклор әсәрләренең жанр төрлелеген (хайваннар турында әкиятләр, тылсымлы һәм көнкүреш әкиятләре; кече фольклор формалары: табышмаклар, санамышлар, бишек җырлары, мәкальләр һ. б.) ачу.

Автор әдәбияты: хикәя, әдәби әкият жанры, шигырьләр. Шигырьнең үзенчәлекләре (ритм, рифма). «Тема» һәм «төп фикер» төшенчәләре. Төрле жанрдагы әсәрләрне практик тану («жанр» төшенчәсен үзләштермичә). Әсәрнең герое, хикәяләүче һәм автор турында күзаллау тудыру.

Текстның халык авыз иҗаты яки автор әсәре булуын билгеләү. Текстның жанр үзенчәлекләре (әкият, хикәя, шигырь, мәкаль, табышмак һ.б.). Әдәби һәм фәнни-популяр текстлар арасындагы аерманы, проза һәм шигырь текстларының аерымлыкларын күрсәтү. Әдәби әсәрдә автор позициясен табу (укытучы ярдәмендә), шулай ук геройның (лирик геройның) кичерешләрен аңлау.

**Укучыларның иҗади эшчәнлеге.** Әдәби әсәрне (яки аның аерым өлешләрен) рольләргә бүлеп уку. Шигырь һәм проза әсәрләрен сәнгатьле укый белү. Интонация, уку темпын аңлы рәвештә сайлый һәм текст үзенчәлекләре нигезендә кирәкле паузалар ясый алу. Дәреслектәге иллюстрацияләрне анализлый белү, аларны әдәби текстлар белән чагыштыру. Кече фольклор жанрларын практик үзләштерү (табышмаклар, санамышлар, эндәшләр), үз текстын иҗат итү һәм аны тәэсирле чаралар (мимикалар, ишарәләр, интонацияләр) ярдәмендә инсценировкалау. Телдән һәм язма рәвештә (аерым җөмләләр һәм зур булмаган сочинениеләр рәвешендә) үзеңнең шәхси күзәтүләрең һәм тәэсирләрең белән уртаклаша алу.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын өйрәнү нәтиҗәләре башлангыч гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартында формалаштырылган төп белем бирү программасын үзләштерү буенча «Туган тел һәм туган телдә әдәби уку» предмет өлкәсе нәтиҗәләренә карата куелган таләпләргә туры килә.

## ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘР

### Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын өйрәнү укучыларда тәрбия эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча тәкъдим ителгән түбәндәге шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр формалаштырачак:

***патриотик һәм гражданлык тәрбиясе:***

- үз Ватаныңа — Россиягә югары кыйммәт итеп карау, шул исәптән илнең тарихын һәм мәдәниятен чагылдырган сәнгать әсәрләрен өйрәнү аша да;
- үзеңнең этномәдәни тәңгәллегеңне һәм Россия гражданины булуыңны аңлау;
- үз илеңнең һәм туган ягыңның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән бәйләнеш тою, шул исәптән сәнгать әсәрләрен өйрәнү барышында фикер алышу аша да;

- үз халкыңа һәм башка халыкларга хөрмәт белән карау, шул исәптән әдәби әсәрләр һәм фольклор әсәрләре аша да шундый ук хөрмәт тәрбияләүгә ирешү;
- әдәби әсәрләр һәм фольклор әсәрләрендә урын алган кыйммәтләргә, әдәп-әхлак нормаларына таянып, һәм гомумән, җәмгыятьнең бер әгъзасы булган кеше, аның хокуклары һәм бурычлары, хөрмәткә лаек булуы һәм абруе, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр турында беренчел күзаллау туу;

***рухи-әхлакый тәрбия:***
- уку нәтиҗәсендә һәм шәхси тормыш тәҗрибәсенә таянып, һәр кешенең индивидуаль шәхес булуын тану;
- тел нормалары, сөйләм әдәбе чикләрендә кешенең хәленә керү, хөрмәт һәм шәфкатьлелек күрсәтү, үз халәтен һәм хисләрен белдерү; башка кешеләрнең тойгыларын аңлау һәм уртаклашу, теләктәшлек күрсәтү;
- яшьтәшләре белән хезмәттәшлек итү, конфликтлар булдырмау һәм бәхәсле хәлләрдән чыгу юлларын табу, шул исәптән әдәби әсәрләр үрнәкләренә таяну;

***зәвык тәрбияләү:***
- мәдәниятебезне хөрмәт итү һәм аның белән кызыксыну, сәнгать төрләренә, үзеңнең һәм башка халыкларның традицияләренә, иҗатына ихтирам белән карау;
- сәнгатьнең төрле юнәлешләрендә, шул исәптән сүз сәнгатендә үз-үзеңне күрсәтергә, танытырга омтылу;
- физик тәрбия, сәламәт яшәү культурасы һәм эмоциональ тотрыклылык формалашу;
- әйләнә-тирә мохиттә өстәмә мәгълүмат эзләгәндә (шул исәптән цифрлаштырылган информацион кырда да), үзеңә һәм башкаларга мөнәсәбәттә сәламәт һәм имин яшәү кагыйдәләрен үтәү;
- үз фикереңне җиткерүнең кулай ысулларын сайлау, сөйләм этикеты нормаларын һәм аралашу кагыйдәләрен үтәү нигезендә физик һәм психик сәламәтлеккә зарар китермәү;

***хезмәт тәрбиясе:***

- кеше һәм җәмгыять тормышында хезмәтнең югары кыйммәт булуын (шул исәптән әдәби әсәрләрдән алынган мисаллар ярдәмендә дә) аңлау, хезмәт нәтиҗәсенә җаваплы караш һәм сакчыл мөнәсәбәт, эшчәнлекнең төрле төрләрендә катнашу күнекмәләре, әдәби әсәрләр турында фикер алышу барышында танышкан төрле һөнәрләр белән кызыксыну;

***экологик тәрбия:***

- текстлар белән эшләү барышында табигатькә сакчыл мөнәсәбәт формалаштыру;
- үзенә зарар китерә торган гамәлләрне кабул итмәү;

***фәнни танып белү кыйммәтләре:***

- дөньяның фәнгә нигезләнгән картинасы турында беренчел күзаллаулар барлыкка килү, шул исәптән кайбер әдәби төшенчәләрне үзләштерү барышында да;
- танып белү мәнфәгатьләре, танып белүдә активлык, инициативалылык, кызыксыну һәм мөстәкыйльлек, шул исәптән әдәби әсәрләрне укуга игътибарлы мөнәсәбәт, уку даирәсен киңәйтүдә активлык һәм мөстәкыйльлек.

**Метапредмет нәтиҗәләр**

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын өйрәнү нәтиҗәсендә, укучыларда түбәндәге танып белү универсаль уку гамәлләре формалашачак.

***Төп логик гамәлләр:***

- төрле текстларны чагыштыру өчен, нигезләр табу, текстларның охшашлыгын күрсәтү;
- аерым бер билге буенча объектларны (текстларны) берләштерү;
- мәкальләрне, әйтемнәрне, фразеологизмнарны классификацияләү өчен төп үзенчәлекне билгеләү;
- укытучы тәкъдим иткән күзәтү алгоритмы нигезендә текстларда закончалыклар һәм каршылыклар табу; текстны тикшергәндә кулланылган гамәлләрнең алгоритмын анализлау, әлеге гамәлләрне мөстәкыйль рәвештә аерып күрсәтү;

- тәкъдим ителгән алгоритм нигезендә өйрәнү һәм гамәли бурычны хәл итү өчен, мәгълүматның җитмәвен ачыклау, җитешмәгән өстәмә мәгълүматны эзләргә өйрәнү;
- текстны анализлаганда, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗәләр ясау.

***Төп тикшеренү гамәлләре:***

- укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, сөйләм ситуациясе нигезендә үз фикереңне җиткерүне планлаштыру;
- биремне үтәүнең берничә вариантын чагыштыру, тәкъдим ителгән критерийлар нигезендә аеруча туры килә торганын сайлау;
- бирелгән план нигезендә катлаулы булмаган кечкенә тикшеренү үткәрү, проект биремен үтәү;
- нәтиҗәләрне формалаштыру һәм аларны текстка ясалган мәгънәви анализ нәтиҗәләре белән дәлилләп ныгыту; тәкъдим ителгән текстны анализлау барышында укытучы ярдәмендә сораулар формалаштыру;
- вакыйгалар, хәлләрнең мөмкин булган үсешен һәм бердәй яки охшаш шартларда аның нәтиҗәләрен фаразлау.

***Мәгълүмат белән эш:***

- мәгълүмат алу, төгәллек кертү чыганагын сайлау: кирәкле сүзлек, белешмәлек һ.б;
- бирелгән эш тәртибеннән чыгып, тәкъдим ителгән чыганактан (сүзлекләрдән, белешмәлекләрдән) төгәл мәгълүматны табу;
- мөстәкыйль рәвештә яисә укытучы тәкъдим иткән тикшерү ысулы нигезендә ышанычлы һәм төгәл булмаган мәгълүматны (сүзлекләргә, белешмәлекләргә, дәреслеккә мөрәҗәгать итеп) танып белү;
- Интернетта мәгълүмат эзләгәндә, өлкәннәр (педагогик хезмәткәрләр, ата-аналар яки аларны алмаштыручы законлы вәкилләр) киңәшен тотып, мәгълүмати иминлек кагыйдәләрен үтәү;
- уку бурычы таләбеннән чыгып, текст, график, видео, аудиоязма хәлендәге мәгълүмат булдыру һәм анализлау;

- таблица, схема рәвешендә китерелгән мәгълүматны аңлау; текстлар белән эшләүнең нәтиҗәләрен күрсәтү өчен, схемалар, таблицалар төзү.

Башлангыч мәктәп курсын тәмамлаганда, укучыда коммуникатив универсаль уку гамәлләре формалаша.

***Аралашу:***

- таныш мохиттә аралашу максатларыннан һәм шартларыннан чыгып, әйтелгән фикерләрне кабул итү һәм үз фикерләрен формалаштыру, хис-кичерешләрне белдерү;
- әңгәмәдәшкә хөрмәт саклау, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү;
- карашлар төрле булу мөмкинлеген тану;
- үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү;
- сөйләмне куелган бурычка нигезләнеп төзү;
- сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар (тасвирлама, фикер йөртү, хикәяләү) булдыру;
- парлап һәм төркемдә эшләү, кечкенә тикшеренү, проект биреме нәтиҗәләре турында кыскача чыгышлар әзерләү;
- чыгыш текстына күргәзмә материал (рәсемнәр, фоторәсемнәр, плакатлар) сайлау.

***Күмәк эшчәнлек:***

- типик шартларда күмәк бурычны үтәү өчен, укытучы тәкъдим иткән планга сыешырлык итеп, үзең өчен кыска һәм дәвамлы вакыт аралыгына максатлар, аңа ирешү алымнарын һәм вакытын билгеләү;
- уртак эшчәнлекнең максатын аңлау, аңа ирешү өчен, күмәк гамәлләр кылу: килешенеп вазифаларны бүлү, уртак эш барышы һәм нәтиҗәсе турында фикер алышу;
- җитәкчелек итү, йөкләмәләр башкару; буйсынырга, каршылыкларны мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә әзерләү;
- үз өлешеңә тигән эшне башкаруда җаваплылык хисе булдыру;
- гомуми нәтиҗәдә үзең керткән өлешне бәяләү;
- тәкъдим ителгән үрнәкләргә таянып, күмәк проект биремнәрен үтәү.

Башлангыч мәктәп программасын тәмамлаганда, белем алучының түбәндәге **регулятив-универсаль уку гамәлләре** формалаша.

***Оештыру:***

- нәтиҗәгә ирешү өчен, уку бурычын хәл итү эзлеклелеген планлаштыру;
- сайлап алынган гамәлләрнең эзлеклелеген булдыру.

***Үз-үзеңне тикшерү:***

- уку эшчәнлегенең уңышы һәм уңышсызлыгы сәбәпләрен билгеләү;
- сөйләм хаталарын һәм текстларны анализлауга бәйле хаталарны булдырмау өчен, үзеңнең уку эшчәнлегеңә төзәтмәләр кертү;
- эшчәнлек нәтиҗәсен текстларны анализлауга куелган уку бурычы белән чагыштыру;
- текстлар белән эшләгәндә җибәрелгән хатаны табу;
- үз эшчәнлеге һәм сыйныфташлары эшчәнлеге нәтиҗәләрен чагыштыру, аларны тәкъдим ителгән критерийлар нигезендә объектив бәяләү.

**Предмет нәтиҗәләр**

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын дүрт ел дәвамында өйрәнү түбәндәге нәтиҗәләрне тәэмин итәргә тиеш:

- татар әдәбиятын дөньякүләм һәм милли мәдәният күренеше, тормышны танып белүнең махсус ысулы, халкыбызның милли-мәдәни байлыгы, әхлакый кыйммәтләрне һәм традицияләрне саклау һәм тапшыру чарасы буларак аңлау;
- татар әдәбияты әсәрләрен өйрәнү нигезендә татар теленең коммуникатив-эстетик мөмкинлекләрен аңлау;
- туган телдәге әдәбиятны укуның шәхси үсеш, үзеңне, дөньяны, милли тарихны һәм мәдәниятне танып белү; мәдәни тәңгәллегеңне тану; татар әдәбиятын системалы укуга ихтыяҗ булдыру өчен, аның мөһимлегенә төшенү;

- укылган әсәрдәге каһарманнар гамәлләренең әхлакый нормалар белән тәңгәллеген ачыклау, әлеге гамәлләрне әхлакый бәяләүне нигезләү;
- метафораларның, сынландыруларның, эпитетларның милли үзенчәлеген аңлау;
- уку күнекмәләрен камилләштерү (кычкырып һәм эчтән уку, интерпретациянең элементар алымнарын белү, әдәби, фәнни-популяр текстларны анализлау һәм үзгәртеп кору);
- татар әдәбияты әсәрләрен уку тәҗрибәсен мөстәкыйль куллану (тыңланган / укылган текст буенча фикер алышуда катнашу, текстка сылтамалар белән үз фикереңне исбатлау һәм раслау; текст үзенчәлеген саклап, тыңлаган яки укыган текстның эчтәлеген кыскача яки тулысынча сөйләү; укылган әсәрләр нигезендә коммуникатив бурычны (төрле адресат өчен) исәпкә алып, телдән хикәя төзү, шигъри әсәрләрне яттан уку);
- кызыксындырган әдәбиятны мөстәкыйль сайлау һәм кызыксыну чикләрен киңәйтә бару;
- өстәмә мәгълүмат алу өчен, белешмә чыганаклардан файдалану.

**Уку елы тәмамланганда, 2 нче сыйныф укучысы:**

*База өлешендә:*

- укыганда, интонацияне дөрес куеп, орфоэпик нормаларны саклап, барлык авазларны ачык һәм дөрес итеп әйтеп, урыннарын алыштырмыйча, иҗекләп түгел, сүзләр белән аңлап дөрес итеп кычкырып укырга һәм кычкырып укудан эчтән (үзлегеннән) укуга күчәргә;
- укылган әсәрнең эчтәлеге турында сораулар бирергә, әңгәмәдә катнашырга;
- укыган әсәрнең темасын һәм төп идеясен мөстәкыйль рәвештә билгеләргә;
- әсәрдәге вакыйгаларның хронологик эзлеклелеген күрсәтергә;

- әсәрнең исемен аның темасы белән чагыштырырга (табигать, яшьтәшләре турында, яхшылык белән яманлык һ.б. хакында);
- кыска монологик сөйләм төзергә (укытучы соравына кыска һәм тулы җаваплар бирергә);
- әдәби геройны характерлый белергә, аның эш-гамәлләрен бәяләргә;
- төрле авторларның 2–3 шигырен яттан сөйләргә өйрәнергә;
- дәреслек белән эшләргә (тышлык, эчтәлек, махсус тамгалар таблица, иллюстрацияләрне таба һәм эшли белергә);
- фольклорның төрле жанрларын аерырга һәм әйтеп бирергә (мәкальләр һәм әйтемнәр, табышмаклар, әкиятләр);
- тексттан тел-сурәтләү чараларын (синоним һәм антонимнарны) табарга;
- әдәби әсәрне рольләргә бүлеп укый алырга;
- шәхси күзәтүләргә һәм тәэсирләргә нигезләнеп, кыска сочинениеләр язарга өйрәнә.

*Предметны тирәнтен өйрәнү өлешендә:*

- укыганда, интонацияне дөрес куеп, орфоэпик нормаларны саклап, барлык авазларны ачык һәм дөрес итеп әйтеп, урыннарын алыштырмыйча, иҗекләп түгел, сүзләр белән аңлап дөрес итеп кычкырып укырга һәм кычкырып укудан эчтән (үзлегеннән) укуга күчәргә;
- укылган яки тыңланган әсәрләрнең мәгънәсен аңларга;
- укылган әсәрнең темасын һәм төп идеясен мөстәкыйль рәвештә билгеләргә;
- әсәрдәге вакыйгаларның хронологик эзлеклелеген күрсәтергә;
- әсәрнең исемен аның темасы белән чагыштырырга (табигать, яшьтәшләре, яхшылык белән яманлык һ.б. турында);
- кыска монологик сөйләм төзергә (укытучы соравына кыска һәм тулы җавап бирергә);
- тексттагы персонажларның портретын сурәтләгән урыннарны табарга, әсәр геройларын (аларның исемнәрен, пор-

третларын, сөйләмнәрен) тасвирлап бирергә һәм аларның эш-гамәлләрен бәяләргә;

- төрле авторларның 3–4 шигырен яттан сөйләргә;
- дәреслек белән эшли белергә (тышлык, эчтәлек, махсус тамгалар, таблица, иллюстрацияләрне табу);
- фольклорның төрле жанрларын аерырга һәм әйтеп бирергә (мәкальләр һәм әйтемнәр, табышмаклар, әкиятләр);
- тексттан тел-сурәтләү чараларын (сынландыру) таба, аларның ролен аңлата алырга;
- сәнгатьле укырга, телдән сурәтләргә;
- сәнгати чаралар кулланып, тасвирлама текст булдырырга;
- шәхси күзәтүләргә һәм тәэсирләргә нигезләнеп, кыска сочинениеләр язарга өйрәнә.

## ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| Тема | Эчтәлек | Укучылар эшчәнлегенең төрләре |
|---|---|---|
| Алтын көз җитте<br>(7 сәгать) | Көзге табигатьнең сокланулы матурлыгы, 1 нче сентябрь – Белем көне турындагы әсәрләр.<br>**Б. Рәхмәт.** «Сара мәктәпкә бара».<br>**Р. Миңнуллин.** «Исәнме, мәктәп!».<br>**Р. Вәлиева.** «Көз»<br>**Г. Хәсәнов.** «Көзге бакча».<br>**Л. Лерон.** «Яфрак бәйрәме».<br>**Ф. Яруллин.** «Көзге табын».<br>**И. Туктар.** «Урман букеты».<br>**К. Тәхау.** «Көзге урман».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**М. Хәсәнов.** «Сара мәктәпкә бара».<br>**Г. Хәсәнов.** «Алтын көз керде урманга». | Текстның эчтәлеген аңлау максатыннан кычкырып уку.<br>Укылган текстның мәгънәсен аңлау.<br>Укылган текст буенча әңгәмә. Сорауларга җаваплар бирү. Текст нигезендә сораулар төзү.<br>Терәк сүзләрне кулланып, текстның эчтәлеген сөйләү.<br>Укылган текстка нигезләнеп, монологик сөйләм булдыру.<br>Әдәби текст белән эш: тел-сурәтләү чараларын табу.<br>Иҗади эш: укылган текст эчтәлеге нигезендә рәсем ясау.<br>Тормыш тәҗрибәсе, шәхси күзәтүләргә таянып сөйләү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу. |

| | | |
|---|---|---|
| Халык авыз иҗаты. Мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар (2 сәгать) | Татар халык авыз иҗатының кече жанрлары. Мәкаль-әйтемнәр. Табышмаклар.<br>Алардагы тематик киңлек. Мәкаль һәм әйтемнәрнең мәгънәләре, аларны тормышта куллану ситуацияләре.<br>Табышмакларны чишүдә зирәклек һәм тапкырлык. | Тыңлау: сөйләмне тыңлап кабул итү, сүзнең яңгырашын һәм мәгънәсен бердәй кабул итү.<br>Сүзлек эше: аңлатмалы сүзлектән табып, сүзләрнең мәгънәсен аңлату.<br>Әдәби текст белән эш: тел-сурәтләү чараларын табу, образлар системасын билгеләү.<br>Татар халык авыз иҗатында кече жанрларның аермасын белү.<br>Иҗади эш: үрнәк нигезендә табышмак иҗат итү. |
| И ямьле дә соң дөнья! (4 сәгать) | Табигать, хезмәт, дустанә мөнәсәбәтләрне, кешенең эчке һәм тышкы матурлыгын чагылдырган әсәрләр.<br>**Л. Лерон.** «И ямьле дә соң бу дөнья!», «Соклангыч дөнья».<br>**Р. Гаташ.** «Зәңгәр ил – балачак иле». | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып уку, кычкырып укудан эчтән укуга күчү.<br>Укылганның эчтәлеген аңлау.<br>Уку диалогы: укылган текстка караган сорауларга телдән җавап бирү.<br>Әдәби текст белән эш: әсәрнең төп фикерен билгеләү, бирелгән мәкальләр арасыннан әсәрнең төп фикеренә туры килә торганын сайлап алу. Төрле язучыларның бер темага язылган әсәрләрен чагыштыру, геройның |

| | | |
|---|---|---|
| | **Г. Тукай.** «Эш беткәч уйнарга ярый».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**Э. Шәрифуллина**. «Алтын балык».<br>**Н. Дәүли.** «Бала болыт». | хис-кичерешләрен сурәтләү чараларын билгеләү, әдәби чараларның текстта урынын табу һәм мәгънәсен аңлау.<br>Текст буенча сораулар төзү.<br>Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эш: укылган текст эчтәлеге буенча рәсем ясау.<br>Проект эше эшләү.<br>Сыйныфтан тыш уку: тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу. |
| Ап-ак кыш килде<br>(5 сәгать) | Кышкы табигать матурлыгын, кышкы урман, кошлар һәм җәнлекләрнең кышкы тормышын чагылдырган әсәрләр. Яңа ел бәйрәме.<br>**А. Алиш.** «Январь».<br>**Г. Афзал.** «Беренче кар».<br>**Б. Рәхмәт.** «Кыш һәм кеше».<br>**Ә. Кари.** «Кошлар туйдырам».<br>**С. Урайский.** «Чыршы янында». | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып уку, кычкырып укудан эчтән укуга күчү.<br>Уку диалогы: укылган текстка караган сорауларга телдән җавап бирү.<br>Әдәби текст белән эш: укылган текстның темасын, сурәтләү чараларын билгеләү.<br>Укылган текстка нигезләнеп, монологик сөйләм булдыру.<br>Иҗади эш: укылган текст эчтәлеге буенча рәсем ясау, тел-сурәтләү чараларын кулланып, тасвирлама текст төзү. |

| | | |
|---|---|---|
| | **А. Хәсән.** «Кыш бабай бүләк өләшә».<br>**Ә. Еники.** «Кышкы урман».<br>**К. Ушинский.** «Дүрт теләк».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**Н. Кәримова.** «Кое чыпчыгы».<br>**Ш. Биккол.** «Урман читендә». | Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Сыйныфтан тыш уку: тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү. |
| Туган илем, туган телем (5 сәгать) | Туган илнең кеше тормышындагы әһәмиятен, туган телнең кадерен, аны саклау кирәклеген һәм Туган ил образын ачучы әсәрләр.<br>**Г. Тукай.** «Туган тел».<br>**Э. Мөэминова.** «Туган телем».<br>**Ә. Рәшитов.** «Кояшлы ил – бәхет иле».<br>**Г. Бәширов.** «Безнең Татарстан».<br>**Л. Лерон.** «Татар баласы».<br>**Р. Фәйзуллин.** «Синеке – илнеке».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**Г. Морат.** «Татар космонавты».<br>**Ә. Синугыл.** «Татарстан җирләре». | Әдәби текст белән эш: укылган текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү, сурәтләү чараларын табу, аларның әһәмиятен һәм ролен билгеләү.<br>Бирелгән мәкальләр арасыннан әсәрнең төп фикеренә туры килә торганын сайлап алу.<br>Уку диалогы: укылган текст эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.<br>Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу. |

| | | |
|---|---|---|
| Яз керде өебезгә<br>(5 сәгать) | Яз айларын, табигатьнең язгы уянуын, кошлар һәм җәнлекләр тормышындагы үзгәрешләрне – әдәбиятта яз образын ачып бирә торган әсәрләр.<br>**Ә. Бикчәнтәева.** «Март аенда».<br>**Г. Бәширов.** «Язгы авазлар».<br>**Н. Мадьяров.** «Кар астыннан чыкты яз».<br>**Ф. Кәрим.** «Яз җитә».<br>**Р. Миңнуллин.** «Яз керде өебезгә».<br>**Э. Мөэминова.** «Май».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**З. Нури.** «Кошларга бүләк». | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып уку, сәнгатьле уку.<br>Әдәби текст белән эш: укылган әсәрнең темасын билгеләү, төрле язучыларның бер темага язылган әсәрләрен чагыштыру.<br>Әдәби тел-сурәтләү чараларын текстtan табу һәм мәгънәсен аңлау, аларның әһәмиятен билгеләү.<br>Текст нигезендә кыска монологик сөйләм әзерләү.<br>Тормыш тәҗрибәсе, шәхси күзәтүләргә нигезләнеп сөйләү.<br>Иҗади эш: тел-сурәтләү чараларын файдаланып, тасвирлама текст төзү.<br>Проект эше эшләү. |

| | | |
|---|---|---|
| Көлке көлә килә<br>(3 сәгать) | Мәктәп, сыйныфташлар һәм дуслар тормышында көлкеле һәм кызыклы хәлләр турындагы әсәрләр.<br><br>**Р. Миңнуллин.** «Малайлар сөйләшә».<br>**Ш. Галиев.** «Онытылган...».<br>**З. Гомәрова.** «Кайда булсын – кесәмдә».<br>**Р. Вәлиев.** «Бу сыйныфка ни булган?».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**М. Мәһдиев.** «Чисталык өчен көрәш».<br>**А. Әхмәтгалиева.** «Әби, Илнур һәм шигырь». | Текстны кычкырып уку, сәнгатьле уку.<br>Уку диалогы: әсәрнең исеме, рәсемнәр һәм ачкыч сүзләргә нигезләнеп, әсәрнең эчтәлеген фаразлау, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.<br>Әдәби текст белән эш: укылган текстның исеме һәм аның эчтәлеге арасындагы тәңгәллекне табу, автор позициясен билгеләү.<br>Укылган текстта хикәяләүче затны үзгәртеп, текст эчтәлеген тулы итеп сөйләү.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләргә бүлеп уку. |

| | | |
|---|---|---|
| Исәнме, җәй!<br>(3 сәгать) | Җәйге табигатьнең матурлыгы, җәйге каникулны кызыклы һәм күңелле үткәрү турындагы әсәрләр.<br>**Р. Вәлиева.** «Исәнме, җәй!».<br>**Ш. Камал.** «Җәйге иртә».<br>**Л. Лерон.** «Җәй көтә безне».<br>**Р. Хисмәтуллин.** «Июль аланы».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**В. Нуриев.** «Җәйге кар».<br>**Г. Морат** «Тылсымлы тел».<br>*Контроль эш.* | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып уку.<br>Уку диалогы: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.<br>Әдәби текст белән эш: әсәрнең лирик героена характеристика, тексттан тел-сурәтләү чараларын табу.<br>Рәсемнәр һәм иллюстрацияләргә карап сөйләү.<br>Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Иҗади эш: тормыш тәҗрибәсе, шәхси күзәтүләргә нигезләнеп, кыска сочинение язу.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу. |

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

Методик ярдәмлектә бирелгән дәрес үрнәкләре укытучыга бары юнәлеш бирү һәм бу дәрестә игътибардан читтә калмаска тиешле төп нәрсәләрне искәртүне генә максат итә.

Дәреслектәге һәр тема өйрәнелә торган әсәр белән бәйләп бирелә. Башлангыч сыйныфларның һәр дәреслегендәгечә, теманы өйрәнүнең башыннан ахырына кадәр белемнәрне укучылар белән таныш персонаж-геройлар – Алмаз, Гөлназ, Нур, Дәреслек үзләштерә. 2 нче сыйныф дәреслегенә аларга яңа герой – Сара кушыла.

Әлеге персонажлар укучылар белән өйрәнелә торган темага һәм куелган уку мәсьәләсенә бәйле сөйләшү алып баралар. Мондый әңгәмәләр традицион рәвештә теманың башында һәм ахырында бирелә. Билгеле, алар һәм төрле коммуникатив юнәлешле биремнәр баланың телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерүгә хезмәт итеп кенә калмыйлар, укучыларның күңелләрен үстереп, әдәби әсәрне өйрәнүгә кызыксыну да уяталар.

Дәреслек ике төрле мәктәпне (татар һәм рус), ягъни ике дәрәҗәдә укуны (предметның база өлешен өйрәнүчеләр һәм тирәнтен өйрәнүчеләрне), димәк, бер-берсеннән бик нык аерылып торган укучыларга белем бирүне күздә тота.

2 нче сыйныф дәреслегендә дә төрле дәрәҗәдә өйрәнелә торган материаллар аерып тәкъдим ителә. Предметны тирәнтен өйрәнүчеләр өчен булган өстәмә өлеш дәреслек битләрендә график сурәт (яшел пунктирлар) ярдәмендә күрсәтелә. Ике дәрәҗәгә аеру әсәр ахырыннан соң бирелгән сорау-биремнәрдә дә чагылыш таба. Татар мәктәпләрендә укучыларның мөмкинлекләре зуррак булуын искә алып, дәреслектә өстәмә материал урнаштырылды. Методик ярдәмлектә татар мәктәбенә генә кагылышлы өлеш зәңгәр төс белән аерып күрсәтелде.

Дәреслектәге биремнәр, аеруча рус мәктәпләрендә, теманы үзләштерүдә артык авырлык тудырмауны күздә тота. Татар мәктәпләре өчен булган өстәмә материаллар, сорау-биремнәр

укучыларның иҗади мөмкинлекләрен, билгеле бер әдәби-теоретик төшенчәләрне тулысынча аңлауларын максат итә.

Телне төрле дәрәҗәдә белгән укучыларга әдәби текстны кабул итү һәм аңлауны берникадәр җиңеләйтү өчен, сүзлекчә китерелә. Бирeдә текстта очраган таныш булмаган сүз, аның татар телендәге синонимы (синоним булмаган очракта урыны буш калдырыла) һәм рус теленә тәрҗемәсе бирелә.

Дәреслектә үзләштерү өчен тәкъдим ителгән әдәби-теоретик төшенчәләр саны күп түгел. Ятлау өчен дә елга 2 – 3 әсәр генә каралган. Предметны тирәнтен өйрәнү өлешендә генә аларның саны 3 – 4.

Үткән материалны кабатлау өчен, 2 нче сыйныф дәреслегендә гомумиләштерергә ярдәм иткән сорау-биремнәр урнаша. Укытучы бу дәресне үзе теләгәнчә, кызыклырак итеп тә үткәрә ала. Бу исә укучыларның мөмкинлеге белән дә бәйле.

«Сабантуй бүләге» рәвешендә тәкъдим ителгән мәкаль-әйтемнәрне белемнәрне ныгыту яки дәрескә йомгак ясау этабында уңышлы кулланып була.

Дәрестән тыш уку өчен кайбер әсәрләр дә дәреслеккә кертелгән. Монда укытучыга сайлап алу мөмкинлеге бар.

Дәреслекнең электрон вариантында, төп материал белән беррәттән, һәр дәрестә куллану өчен өстәмә заманча материаллар урнаштырылды: рәсемнәр, интерактив форматтагы эш төрләре, биремнәр һ.б. Алар балаларның кызыксыну даирәләрен, яшь үзенчәлекләрен исәпкә ала. Шулай ук бирeдә аерым текстларның аудиоязмалары бирелә. Текст белән эшләгәндә, аларны тыңлатып була.

Дәреслектәге уку материалы видеодәресләр форматында да тәкъдим ителә. 2 нче сыйныф өчен барлыгы 12 тема буенча күләме ягыннан зур булмаган видеороликлар булдырылды. Аларның эчтәлеге Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә, һәм алар Үрнәк эш программалары нигезендә әзерләнде. Видеодәресләрнең төп максаты – укучыларны яңа материал белән таныштыру, аны презентация яки анимация чара-

лары ярдәмендә аңлату. Видеодәресләр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында урнаштырылды.

Шунысын истә тотыйк: сыйныфтагы укучыларның гомуми мөмкинлеген һәм һәр укучының аерым мөмкинлекләрен бары укытучы үзе генә белә. Шуңа күрә бирелгән дәресләр үрнәгендә генә эш итеп булмый. Бу әсәрне уку, сүзлек белән эшләү, сорауларга җавап бирү, әңгәмә нинди рәвештә үткәреләчәге укытучыдан тора. Әлбәттә, ул әлеге эш алымнарын үзенчә куллана ала. Өстәмә сорау-биремнәр, әңгәмәне үзе сайлаган темага оештыру укытучы иркендә. Шуңа дәрес үрнәкләрендә бу өлешкә киң тукталынмады. Текст белән эш телне яхшы белмәүче балалар өчен дөрес уку һәм укыганны аңлау, гади сорауларга җавап бирүдән дә артмаска мөмкин. Иң мөһиме – нәтиҗә ясау һәрвакыт баланың тормыш тәҗрибәсе белән бәйле булганда яхшы. Укучы әдәби әсәр эчендәге вакыйга һәм кичерешләрне үз күңеле аша үткәрә алырга тиеш. Бала бер генә мизгелгә шул әсәрдәге тормыш белән яшәп алганда гына, укуның файдасы булачак һәм шәхескә юнәлтелгән максатка хезмәт итәчәк.

## ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕНЕҢ ҮРНӘКЛӘРЕ

Методик ярдәмлектә бирелгән дәрес үрнәкләре укытучыга бары юнәлеш бирү һәм бу дәрестә игътибардан читтә калмаска тиешле төп моментларны искәртүне генә максат итә. Дәрестә әлеге үрнәкләрдәгечә генә эш итеп булмый, чөнки сыйныфтагы укучыларның гомум һәм шәхси мөмкинлекләре исәпкә алынырга тиеш. Әсәрне уку, сүзлек белән эшләү, сорауларга җавап бирү, әңгәмәнең ни рәвешле үткәрелүе укытучы ихтыярында. Өстәмә сорау-биремнәр төзегәндә, үзе сайлаган темага әңгәмә оештырганда, ул үзе теләгәнчә эшли ала. Шуңа күрә дәрес үрнәкләрендә бу өлешкә киң тукталмадык.

**Тема**: Әйдәгез мәктәпкә!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – китапны ярату, дәреслеккә сак караш, китап уку, туган телдә аралашу теләге туу; дуслык кадерен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү; чагыштыру һәм нәтиҗә ясау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – әдәби уку предметының эчтәлеген аңлау, дәреслек белән эшли белү; Бари Рәхмәтнең «Сара мәктәпкә бара», Роберт Миңнуллинның «Исәнме, мәктәбем!» шигырьләренең эчтәлегенә төшенү, аның темасын (нәрсә турында булуын) аңлау һәм әйтеп бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр. Р. Миңнуллинның балалар өчен китаплары (Миңнуллин Р. Дөньядагы зур алма: балалар өчен шигырьләр, әкиятләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992; Миңнуллин Р. Качышлы уйнаганда: Балалар өчен шигырь = Прятки: Стихотворение для детей. – Казан: Мәгариф,

2009; Миңнуллин Р. Кунакка килегез!: Балалар өчен шигырьләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008).

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укытучы узган уку елында «Әдәби уку» дәресләренең ничек, нинди вакыйгалар белән хәтердә калуы турында кызыксына.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар белән бергәләп яңа дәреслекне кулга алу, аның тышлыгы, геройлары белән танышу, аларның исемнәрен атау. Тышлыкта – яңа кыз Сара, әмма балалар аның белән таныш түгел, алар аны Гөлназ дияргә мөмкин. 1 нче сыйныф дәреслеген искә төшерү аша Сараның яңа дустыбыз икәнен искәртәбез. «Кем икән ул? Быелгы китабыбыз безгә нинди яңалыклар, кызыклы әсәрләр бүләк итәчәк?» сораулары аша китап белән танышуга күчәбез.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Шартлы билгеләр белән танышкач, укытучы автор сүзләрен укый. *Танышырбыз, Өйрәнербез, Белербез һәм Исеңдә тот*! өлешләренә аерым игътибар кирәк.

Дәреслек репликасын балаларның үзләреннән укытырга мөмкин. 6 нчы биттәге рәсемдә таныш геройлар арасында инде яңа герой, яңа дус булачагы ачыклана.

Укытучы, Сара белән дусларыбыз безне үзләре таныштырачагын әйтеп: «Әйдәгез, үзләрен тыңлыйк», – ди, һәм Алмаз, Нур, Гөлназ, Сара репликалары укыла.

«Безнең яңа дустыбыз кем икән? Ул нинди кыз?» дигән сорауларга җавап алгач, рус телендә белем бирүче мәктәп укучыларының җәйге ялны ничек уздырулары турында сөйләшү дәрес бу-

лыр, чөнки аларның кабат бу сорауга әйләнеп кайту мөмкинлеге юк, тирәнтен өйрәнүчеләргә бу алда каралган.

Алга таба Дәреслек сораулары нигезендә әңгәмә дәвам итә. Нур репликасы «Сара мәктәпкә бара» шигырен уку өчен юл ача. Укытучы шигырьне укуны төрлечә оештыра ала. «Сара мәктәпкә бара» шигырен сәнгатьле итеп укытучы укый яки аудиоязмада тыңлана. Видеодәрес материалыннан да файдаланып була. Бу – укучыларның әзерлеге, дәреснең төре һәм максат белән бәйле. Әмма авыр укый торган баланың беренче дәрестә үк күңелен кайтармау кирәк. Шигырьдән соң аңлашылмаган сүзләр калганмы, шул хакта кызыксыну, кирәк булса аңлату тиеш. Сөйләм байлыгы аз булган укучылар белән Сараның сумкасында нәрсәләр барлыгын шигырь һәм рәсем ярдәмендә санап чыгарга мөмкин. Бу бирем сүз байлыгын арттырырга булышыр.

Сораулар һәм биремнәргә җавап бирү:

1. Шигырь мәктәпкә бару (шатлыгы) турында.
2. Сара шатлана. Сәбәбе – мәктәпкә бару. Шигырьнең ахыргы куплеты белән дәлилләнә.
3. Балага шатлык хисе таныш булыр. Сәбәбен ачыклау өчен, сорауны икенче төрле бирә алабыз: «Син кайчан шатланасың? Синең нәрсә өчен шатланганың бар?». Шатлык хисенең сәбәпләрен мөмкин кадәр киңәйтү яхшы.

Шатлык өчен сәбәпләр бик кечкенәдән башлап бик зурга кадәр үсә. Әмма матди сәбәпләр тудырган шатлыкка караганда рухи канәгатьлектән туган шатлыкны беренчел итеп танытуга омтылыш кирәк. Әйтик, син утырткан гөл чәчәк атса, матур булып кояш чыкса, өйгә әни кайтып керсә, сиңа яңа чаңгы алып кайтсалар, якын дустың белән очрашсаң, «биш»ле алсаң, туган көнеңә дусларың килсә һ.б.

Сара репликасындагы сорауга нигезләнеп, сөйләшү үткәрә алабыз. «Мансурның шатлыгы» хикәясе шатлык хисенә капма-каршы хис барлыгын аңларга ярдәм итә. Хикәягә нигезләнеп, иң элек Мансурның кичерешләрен санап чыгарга мөмкин. Аңлашылмаган сүзләр ачыклана. Мансурның хатасын (саранлык) табалар.

Хикәяне укып, шатлык хисен өйрәнгән кебек, *кайгыру, борчылу* кебек хисләрнең дә нинди хис булуы, нинди сәбәпләрдән тууы ачыклана.

Дәреслек соравына җавап табыла.

«Күпне өмет итсәң, аздан да коры калырсың» гыйбарәсе (*мәкаль* төшенчәсе таныш түгел, әмма укытучы аны искәртә ала) ни өчен бирелде икән? Аның мәгънәсе ничек? (Күпне теләсәң, саранлансаң, бөтенләй бер әйберең дә булмас.) Ул шигырьдәге Саранымы, әллә хикәядәге Мансурны бәяләргә ярдәм итәме?» дигән сораулар ярдәмендә мәкальнең мәгънәсе ачыклана.

11 нче биттәге Дәреслек биреме укучыга үзенең җәйге ялы турында матур итеп сөйләүне таләп итә. Моның өчен Нурның ярдәмен аңлату кирәк. Ул сөйләмнең тасвирлы, матур булуын күрергә ярдәм итәр.

**Әдәби сөйләм һәрвакыт нәфислеккә, матурлыкка, тасвирлылыкка омтылырга тиеш.**

Укучыларның сөйләменнән соң җәен табигать кочагында физик ныклык, сәламәтлеккә ярдәм итә торган уеннар хезмәт белән бәйләнеп барырга тиеш. Телефон, компьютерда уйнау, телевизорны күп карау зыянлы дигән нәтиҗәгә киленә.

«Ә безнең дусларыбыз бу хакта ничек уйлый икән?» дип, Алмаз, Гөлназ, Сара репликалары белән танышуны дәвам итәбез. Гөлназ куйган сорауга («Мәктәп кемнәрне сагына икән?») җавап бирелә.

Роберт Миңнуллинның «Исәнме, мәктәп!» шигыре белән танышыла, сүзлек эше үткәрелә һәм сорауларга җавап бирелә. Бу урында авторның китапларын күрсәтеп, алдагы сыйныфта өйрәнгән шигырен искә төшереп китәргә дә мөмкин. Бу дәрестә дә хис, хисләрне сөйләмдә бирү ысулына (интонация), сөйләмне матур һәм тәэсирлерәк итү чараларына әһәмият бирелә. Укучыларның шигырьдән бөркелеп торган күңел җылысын, әдәп, хезмәткә хөрмәт, тормышның матурлыгын тоюларына ирешү яхшы. Моның өчен шигырьдәге һәр фикергә игътибар бирү кирәк. Геройның (*лирик герой* төшенчәсе укучыга таныш түгел) хисләре турында сөйләшү дәвам итә. Ул мәктәпне ярата (сагынган, очрашуны түземсезлек белән көткән, «мәктәбем» дип дәшә, мәктәп тә аны

сагынган, зарыгып көткән дип уйлый), «ул язга хәтле сау булыгыз» дип, җәйге ял иткән урыннары белән саубулашкан, яңа уку елын «хәерле сәгатьтә» дип, «биш»легә генә укырга теләк белән башлый. Болар геройның әдәплелеген, һәрнәрсәне күңеле аша үткәреп, аларга җылы мөнәсәбәт саклавын күрсәтә.

7 нче сорауга җавап биргәндә, укучы үз мәктәбенә булган җылы карашы, аны яратуы турында шул рухта сөйләргә омтылсын иде.

**Бала үзе яшәгән мохитне ярату аша тормышны яратырга өйрәнә, шуның өчен ул һәр яхшыга мәхәббәт күзе белән карарга тиеш.**

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучыларның җәйне ничек үткәрүләре, мәктәпкә ничек әзерләнүләре турында сөйләшү буларак оештырырга мөмкин.

Дәреснең бу өлешендә «Исәнме, мәктәп!» шигыренең герое турында сөйләтергә була. Ул шигырьне һәм аның төп фикерен аңларга ярдәм итәчәк.

Геройны күз алдыңа китереп тасвирларга кушарга мөмкин. Моны күмәк башкарганда, һәр укучы аның бер сыйфатын атый. Ахырдан гомумиләштереп нәтиҗә ясала.

Әйтик, кояшта янган, буйга үсеп киткән, ял иткән, тәненә көч җыйган (физик яктан нык); күңеле шат, зур дәрт белән укырга әзер; шул ук вакытта ул тыйнак һәм әдәпле, нечкә күңелле (урманнар, кырлар белән хушлашып килгән.

Шигырьдәге герой үз исеменнән генә сөйләми, «без» ди, димәк, ул бөтен укучыларны күздә тота. «Ә син аның белән килешәсеңме? Синең хисләрең аныкына охшашмы?» кебек сораулар белән укучының хисләрен әйттерәбез. Дәрестәге фикерне йомгакларга «Сабантуй бүләге»ндәге мәкаль ярдәм итәр.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

Җәйге ялны ничек үткәрү турында сөйләшү өчен сораулар язарга.

Мәктәпкә ничек әзерләнүең турында кыскача сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала. Өй эше һәрвакыт аңлатылып, укучыдан нәрсә көтелгәнлеге төшендереп бирелергә тиеш! Кирәк булганда үрнәк тә күрсәтелә, эшләп карала. Укучы өй эшен мөстәкыйль үти алсын өчен, ул сыйныфта эшләп каралган биремгә якын булырга тиеш.

**Тема:** Килеп җиткән алтын көз

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигатьтәге үзгәрешләрне күзәтә, аның матурлыгын күрә белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, үзбәя; иҗади күзаллау; күзәтә һәм нәтиҗә ясый алу; мәгълүматлы булу, әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Резеда Вәлиеваның «Көз» шигыренең эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирү белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дәреслекнең 16 нчы битендәге ике рәсемне чагыштыру һәм аларның берсендә җәй, икенчесендә көз сурәтләнүен ачыклау. Бу – дәрестә табигатьтәге көзге үзгәрешләр турында сөйләшүне аңларга ярдәм итә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

«Килеп җиткән алтын көз» дигән тема укучыларга җиткерелә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укучылар Гөлназ һәм Сара репликалары аша, Нур ярдәмен файдаланып, җәй һәм көз турында үзләре сөйлиләр. Сөйләмнең башкаларны җәлеп итәрлек матур булуына омтылу кирәклеген искәртү һәм аның үтәлешен тәэмин итү кирәк.

Укытучы Резеда Вәлиеваның «Көз» шигырен укуны үзе теләгәнчә оештыра ала, әмма сәнгатьле уку үрнәге бирү зарур. Сүзлек белән эш шигырьне тәэсирле, сурәтле, бизәкле иткән сүзләрне табуга бәйләнештә бара ала.

Мәсәлән, *алтын көз* гыйбарәсенең мәгънәсен ачыклау. Ни өчен алтын көз дип әйтелә? (Кояшлы көннәрдә бөтен дөнья алтын төсле кызгылтсары булып нур чәчеп тора.) Алманың тәме турында ничек әйтелә? (Балга манып алганмыни.) *Кояш карап тора*, *гөмбә утыра көлеп* гыйбарәләре ачыклап кителә (кояш һәм гөмбәгә җанлы зат сыйфатлары бирелгән).

Нәтиҗә ясаганда, шигырь тудыру өчен, авторның рифмалы сүзләр белән генә түгел, телен дә бизәкле, сурәтле (образлы) итүе күрсәтелә.

Шигырь белән танышкач, сорауларга җавап бирүгә күчәбез. *2 нче сорауда* түбәндәге тамга тора 4. (Мондый тамгалар 1 дән 6 га кадәр.) Моны укучыларга аңлатырга кирәк. Сорау артындагы бу билге әлеге биремне үтәү тәртибе белән танышуны сорый. Ул китап ахырында «Кулланма ярдәмлек» исеме белән бирелә. Бу очракта эчтәлекне кыскача сөйләргә әзерләнү тәртибен белдерә. Беренче тапкыр бу биремне укучылар белән бергәләп үтәү яхшы булыр. Әсәрнең темасын «Көзге матурлык» дип атарга мөмкин. Әсәрнең мәгънәви өлешләре бу очракта шигырь куплетларына тәңгәл, беренче куплет кына ике фикерне берләштерә, төп фикерләрне түбәндәгечә биреп була: *Җәй үтеп көз килгән, // җимешләр өлгергәч, бакча тагын да матур, алмалар уңган, урманда да бик ямьле, балалар очыргыч ясап, киек казлар артыннан очыра.*

Шигырьдәге калган юллар әлеге фикерләрне тулыландырып кына тора, яңа фикер җиткерми.

*3 нче сорау* интонация, мимика мәгънә һәм хисне белдерүдә бик әһәмиятле нәрсә икәнен аңлатуны таләп итә. (Кайвакытта *кадерлем* сүзе дә җанны өшетә, *сөйкемсез* сүзе дә күңелгә май булып ята алырлык интонация белән әйтелергә мөмкин.)

**Сүзне әйтү генә түгел, ә аны ничек итеп әйтү күпкә әһәмиятлерәк.**

*4 нче сорау* хис һәм интонация уртаклыгын ачып бирергә ярдәм итә. Бу дәрестә дә хис, аны аңлау һәм башкаларга җиткерүгә игътибарны юнәлтә.

*5 нче сорау рифма* төшенчәсен искә төшерүне сорый.

*6 нчы сорауга* җавапларны парлап сыйныфташларына тәкъдим итә алалар. Бу – хисне сөйләмдә дөрес чагылдыру күнекмәсе булып хезмәт итә.

*11 нче сорау. Кояш карый, гөмбә көлә (көлеп утыра)* гыйбарәләрендә җанлы затка, бигрәк тә кешегә хас сыйфатларны җансыз предметларга, әйберләргә күчереп, тәэсирлелекне арттыру (образлылык) өчен кулланылуын аңлатабыз. Җөмләләрне чагыштырырга мөмкин: *Күктә кояш бар, урманда гөмбә үсә // Күктә кояш карап тора, урманда гөмбә көлеп утыра*. Моның кешеләштерү, сынландыру икәнен әйтеп китү мөһим, әмма ул төшенчә буларак бирелми. Укучылар аның белән берничә дәрес соңрак очрашачаклар.

Алга таба «Көзге алмалар» хикәясе укыла. Аның буенча әңгәмә үткәреп, Хөрмәтле Дәреслек соравына җавап бирү күздә тотыла.

Нәтиҗә ясарга «Сабантуй бүләге» ярдәм итәр.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Көз көне табигать нинди үзгәрешләр кичерә?

Җәй һәм көзне сурәтләп бирү өчен, нинди матур гыйбарәләр кулланырга була?

«Көз» шигыре нәрсә турында, аны кем язган?

Шигырьнең төп фикерләрен әйттереп, тагын башка сораулар ярдәмендә белемнәрнең үзләштерелешен барлап чыгарга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

1. 16 нчы биттәге ике рәсемне чагыштырып, көз җәйге табигатьне ничек үзгәртүе турында сөйләргә әзерләнергә. Нурның ярдәме итеп 17 нче биттәге терәк сүзләрне дә файдаланырга мөмкин.
2. Шигырьне сәнгатьле итеп укырга, аның эчтәлегеннән чыгып сораулар әзерләргә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Көзге бакча

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – бакчада ел фасылына бәйле үзгәрешләрне, көзнең матурлыгын күрә белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, үзбәя; мәгълүмат алу, күзәтә һәм нәтиҗә ясый алу, текстны тикшергәндә кулланылган гамәлләрнең алгоритмын анализлау, әлеге гамәлләрне мөстәкыйль рәвештә аерып күрсәтү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Гарәфи Хәсәновның «Көзге бакча» хикәясенең эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Резеда Вәлиеваның алдагы дәрестә өйрәнелгән «Көз» шигыренә (татар мәктәпләрендә «Күңел күзе» хикәясенә дә) нигезләнеп, табигатьтә һәм бакчаларда көзге үзгәрешләр турында әңгәмә үткәрелә. Өйгә бирелгән биремнәр тикшерелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укытучы дәреслек геройларының нәрсә турында әңгәмә коруларына игътибар иттерә, укучылар сыйныфта әлеге диалог белән танышалар. Аларның нәрсә турында сөйләшүләрен ачыклау бу дәреснең темасын билгеләргә ярдәм итә. «Көзге бакча» темасы укучыларга җиткерелә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Иң элек укучыларның бакча турында күзаллаулары белән кызыксынып, «Нинди җир ул бакча, анда нәрсәләр үсә?» кебек сораулар белән укучыларның карашларын киңәйтергә мөмкин. Шәһәр мәктәпләре өчен бу бигрәк тә әһәмиятле. Ул сөйләм телен баетырга да ярдәм итә, әйләнә-тирә турында мәгълүматны да арттыра. Гарәфи Хәсәновның «Көзге бакча» әсәре күзәтү рәвешендә язылган, тасвирлама формада. Ул сүзләр ярдәмендә картина тудыра. Аны укыганда, күз алдында шушы бакчаның сурәте гәүдәләнеш алырга тиеш. Моңа ирешү өчен, укучының үзе күңелендә торган, тормыш тәҗрибәсе белән хәтеренә кергән бакча булу яхшы. Шуның өчен хикәяне укыганчы, укучыга бакча рәсемнәре тәкъдим итәргә һәм бакча турында әңгәмә коруга вакытны кызганмаска кирәк.

Укытучы Гарәфи Хәсәновның «Көзге бакча» әсәрен укуны үзе теләгәнчә оештыра ала. Хикәяне сәнгатьле итеп укытучы укый яки аудиоязмада тыңларга мөмкин. Укыганнан соң, баланың текстны тулысынча аңлавына ирешү юнәлешендә эшләү сорала.

Әсәрдә нәкъ сентябрь аендагы бакча сурәтләнүен искәртергә була. Бу вакытта, чыннан да, бакчада бары иң соң өлгерә торган алмалар гына кала.

Сүзлек белән эш, тексттагы вакыт агышын, эзлеклелекне тотып алырга ярдәм итү аның эчтәлеген хәтердә калдырырга булыша. Әйтик, башта кура җиләкләре җыела, алар артыннан иртә өлгерә торган алмалар өлгерә.

1–4 нче сорауларга җаваплар бирү текстны беренчел үзләштергәндә кулланыла ала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Бакча нинди урын ул? Көз килгәндә, бакчада нинди үзгәрешләр була?» кебек сорауларга балалар гомуми күзаллау ярдәмендә җавап бирә.

«Гарәфи Хәсәновның «Көзге бакча» хикәясендә бакчадагы нинди үзгәрешләр күрсәтелә? Автор көзге алмаларны ничек сурәтли? Шул урынны табып укы» һ.б. сораулар белемнәрне ныгытуга ярдәм итә. Дәреслектәге 5, 6 һәм 8 нче сорау һәм биремнәрне дә биредә кулланырга мөмкин.

Татар мәктәпләрендә «Күңел күзе» хикәясен укып әңгәмә оештырыла.

Бакчада көзге эшләр, табигатькә сакчыл караш, хезмәтнең нәтиҗәсе, өлкәннәргә булышу турында һәм Мансурның хатасын (әнисенә булышмау, йорт эшләреннән читләшү, әнисенә каршы әйтү, табигатькә миһербансызлык – куяннарга капкын кую) анализлап, нәтиҗә ясау сорала.

**VI. Өй эше бирү.**

Көзге бакчаның рәсемен ясарга (7 нче сорау) яки көзге бакчаны сурәтләп, кечкенә хикәя язарга кушарга.

**VII. Рефлексия.**

Укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Яфраклар ява җиргә *(Музыка һәм хезмәт дәресе белән интеграль дәрес итеп үткәрү мөмкинлеге дә бар.)*

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигать матурлыгын күрә һәм аның белән хозурлана белү, хезмәтнең югары кыйммәт булуын тану, аралашу әдәбенә өйрәнү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, мәгълүмат алу; иҗади күзаллау, күзәтүчәнлек булдыру һәм нәтиҗә ясый алу; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Ләбиб Леронның «Яфрак бәйрәме» шигыренең эчтәлеген аңлау, укылган әсәр буенча сорауларга җавап бирә белү; шигырьдәге тел-сурәтләү чараларын табу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укытучы:

– Укучылар, әйдәгез, көз килгәнне күрсәтә торган төп билгеләрне санап карыйк, – дип тәкъдим итә ала. Укучыларның җавапларын тыңлагач:

– Ә менә Алмаз ниндидер буран турында сөйли, әллә ул ялгыша микән? – дип, сүзне дәреслеккә күчерә ала.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алмаз, Сара, Гөлназ репликаларын укыгач, укучылар бүгенге дәрестә көзге яфраклар, яфрак бураны турында сөйләшәчәкләрен

әйтәләр. Укытучы теманы, төгәл формалаштырып, укучыларга җиткерә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

http://www.youtube.com/watch?v=Ss_gYxkUV7k сылтамасы аша кереп, яки ирекле эзләү ярдәмендә «Ләбиб Лерон. Яфрак бәйрәме» җыры дип язып, Интернеттан әлеге җырны укучылар белән тыңларга мөмкин. Күрсәтелгән юллама аша кергәндә, ул караоке форматында, куллану өчен бик уңайлы. Җырны тыңларга, кушылып җырларга да була. Берничә кат тыңлау нәтиҗәсендә, җыр балалар күңеленә урнашып та кала.

Шигырьне китаптан уку, сүзлек белән эш, сорауларга җавап бирүне укытучы төрлечә оештыра ала.

Әмма дәреслек геройлары репликасына әйләнеп кайтып:

– Ни өчен Алмаз яфраклар коелуны урамда буран дип белдергәндә, Сара аны ялгыша дип уйлады икән? Сез бу хакта уйланмадыгызмы? Буран нинди була? – сораулары аша Алмазның яфракларның бөтерелеп уйнап очуларын кар буранына охшатып, аны буран дип атавын ачыклыйбыз. Табигатьтә яфрак коела гына. Әлеге алымны «Яфрак бәйрәме» шигыренең исемендә үк табалар: *Яфрак бәйрәме* – бәйрәмдә бөтерелеп бию, уйнау, күңел ачу күренешләре; яфракларның күмәкләшеп, бөтерелеп, төрле хәрәкәтләр ясавын да шагыйрь бәйрәм дип атый. *Яфрак ява* дигәндә, ул аны кар яки яңгыр яву күренешенә охшата. Димәк, Алмаз да, шагыйрь дә яфрак коелу күренешен, чынбарлыктагы башка күренешләргә охшатып, төрле сүзләр белән белдерәләр. Бу – сөйләмне тәэсирле, матур итә. Ләкин күренешне, әйберне берсен икенчесе ярдәмендә аңлату аларның уртак, охшаш якларына гына нигезләнә ала. Укучылар шул хакыйкатьне аңларга тиеш.

**Образлы фикерләү, образлы күзаллау иҗат мөмкинлекләрен киңәйтә. Сәнгать әсәре туугa сәбәп була.**

Алга таба Хөрмәтле Дәреслек тәкъдим иткән «Яфраклар сере» хикәясе укыла. Хикәянең герое Айсылуның күзаллавы аша табигатьнең бик кечкенә бөртегендә дә бик күп матурлык, камиллек

ятканын күрергә мөмкин. Укучылар тирә-якны күзәтергә, образлы фикер йөртергә, хезмәтне яратырга, вакытны файдалы үткәрергә өйрәнерләр.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Яфрак бәйрәме» шигырендә «Яфраклар сере» хикәясенә һәм тормыш тәҗрибәсенә нигезләнеп, табигать матурлыгы, көзге яфрак коелу күренешен тасвирлап сөйләп бирүне оештырырга була.

Дәреслекнең 27 нче битендәге рәсемгә карап, «Яфраклар ява» дигән темага сөйләү өчен партадашыңа сораулар бирү текстны үзләштерергә булыша. Җырны кабат бергәләп җырлап карарга тәкъдим ителә.

Укучылардан аларның бу күренешне ничек күзаллаулары, нинди сүзләр белән тасвирлап бирә алулары турында сорашу да мөмкин. Берничә төрле яфракны күрсәтеп (алдан әзерләп), укучыларның аларны нәрсәгә охшатулары, нәрсә ясаганда куллана алулары белән кызыксыну образлы күзаллауга мисал булачак.

«Сабантуй бүләге» нәтиҗә ясарга ярдәм итәчәк.

**VI. Өй эше бирү.**

«Яфрак бәйрәме» шигырен сәнгатьле итеп укырга һәм аның нинди хисләр уятуын сыйныфташларына сөйләргә өйрәнергә. Укучыга үзе белән дәрескә берничә көзге яфрак алып килеп, сыйныфташларын таныштырырга (нинди агачныкы, нинди төстә, нәрсәне хәтерләтә һ.б.)

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Көзге табын

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – хезмәткә хөрмәт һәм өлкәннәргә ярдәм итүгә теләк уяну; табын әдәпләрен белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү; мәгълүмат алу, иҗади күзаллау, тамга-символик чараларны куллану; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Фәнис Яруллинның «Көзге табын» шигыренең эчтәлеген аңлау, шигырь эчтәлеге нигезендә сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру.

Дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Көзге уңыш, көз өлгерә торган яшелчә һәм җиләк-җимешләр турында әңгәмә корып алырга дәреслек геройларының диалогы ярдәм итә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укытучы тактага сөлге өстенә куелган зур түгәрәк икмәк рәсеме урнаштыра.



Тактаның икенче бер почмагына нур сибеп торган кояш куела. Укытучы өстәленә дәреслекнең 31 нче битендәге рәсемдә булган һәм анда булмаган яшелчә һәм җиләк-җимеш рәсемнәре (бөтенесе бер зурлыкта) куела. Укучылар такта янына чыгып рәсемне ала һәм аның бер сыйфатын әйтеп, тактага, икмәк тирәли түгәрәкләп, магнит белән беркетеп куя. Мәсәлән, *алма – баллы, татлы, түгәрәк* һ.б. дип әйтергә мөмкин. Нәтиҗәдә уртасында икмәк торган табын барлыкка килә. Укучылар аның көзге муллыктан тезелгән

табын икәнен әйтәләр. Теманы шулай ачарга мөмкин. Тактадагы бу натюрморт шул килеш калырга тиеш. Ул алда кирәк була.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алга таба Фәнис Яруллинның «Көзге табын» әсәре белән танышуны әсәр исеме нигезендә эчтәлекне фаразлаудан башларга да мөмкин. Сүзлек белән эш, сорауларга җавап бирүне видеодәрескә нигезләнеп эшләргә була.

Сорауларга җаваплар табылганнан соң, шигырьдәге:

Яңа пешкән күмәчтер

Кайнар кояш төслесе, – дигән юлларга игътибар иттерелә.

Укучылар «Нинди сыйфатларына нигезләнеп, шагыйрь күмәчне кояш төсле дип атый алган икән?» дигән сорауга җавап эзлиләр (төсе, формасы, кайнар булуына карап. Кояш та, икмәк тә – яшәү чыганагы).

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреснең бу этабында дәреслекнең 31 нче битендәге рәсем һәм «Сабантуй бүләге» файдалы булыр.

**VI. Өй эше бирү.**

Фәнис Яруллинның «Көзге табын» шигырен хикәяләп сөйләргә әзерләнергә.

Шәхси күзәтүләргә нигезләнеп, көзге табын турында кечкенә тасвирлама хикәя төзеп язарга.

Көзге табын рәсемен ясарга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Урман букеты

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – туган җир матурлыгын күрә, башкалар белән уртаклаша белү; табигатьтәге үзгәрешләрнең сәбәбен, серен аңларга, күбрәк укырга, күбрәк белергә теләк туу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү; иҗади күзаллау, күзәтүчәнлек; үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Идрис Туктарның «Урман букеты», Касыйм Тәхауның «Көзге урман» хикәяләренең эчтәлеген аңлау, уку күнекмәләрен ныгыту.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру.

Дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәресләрдәге белемнәргә нигезләнеп, көзге урмандагы үзгәрешләр турында сорауларга җавап табарга мөмкин. «Агачлардагы үзгәрешләр, җәнлекләрне очратып буламы, нинди кошларны күрергә мөмкин? Нинди җимешләр калды икән?» кебек сораулар ярдәм итәр.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек геройлары әңгәмәсе уку мәсьәләсен куярга мөмкинлек тудыра. Аларның сөйләмендә *чәчәк бәйләме* гыйбарәсе берничә тапкыр кулланыла. Укучы бу сүзне аңлыймы? Әгәр сорау бирүче булмаса, укытучы әлегә бу сүзне аңлатмый тора. Алмаз репликасы дәреснең темасын ача.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Хикәянең исеме укыла һәм «Нәрсә ул букет?» дигән сорау ачыклана.

Хикәянең беренче ике җөмләсен укыгач, сорау куела: «Урманда көз көне нинди букет (чәчәк бәйләме) ясарга мөмкин?» Укучы-

ларның исенә төшерергә кирәк: әйберләрдәге охшаш сыйфатка нигезләнеп, бер әйберне икенчесенең исеме аша белдерергә була. Укучылар яфраклары төрле төскә кергән агачны чәчәк бәйләме – букет дип атарга мөмкин икәнлеген уйлап табалар.

Дәреслекнең 34 нче битендәге рәсемгә нигезләнеп, урман букеты дип аталган агачның нинди агач, аңа нинди сыйфатлар хас икәнлеген, кайда үсүен бергәләп фаразлап карыйлар. (Очып йөргән яфраклар аның имән икәнлеген, артта бик күп агачлар булу аның урман эчендә үскәнлеген, ике чыршыдан әз генә алдарак торганлыгын, бик тә юан, мәһабәт агач булуы турында әйтү мөмкинлеген бирә.)

Алга таба хикәяне укып чыгабыз. Хикәяне сәнгатьле итеп укытучы укый, яки аудиоязмада тыңларга мөмкин. Фаразларны нәтиҗә белән чагыштырабыз.

*Букет, колач* сүзләренең мәгънәсен ачыклаганда, *гөлләмә* сүзенең матурлыгына игътибар иттерү яхшы. Имәннең юанлыгын өч баланы кулларын кулга тоташтырып, түгәрәкләп бастырып аңлатырга мөмкин.

Сүзлек белән эшне сорауларга җаваплар табу рәвешендә дәвам итәләр.

Хикәянең кем исеменнән сөйләнүен ачыклап (Нуриянең абыйсы), хикәяләүченең затын үзгәртеп сөйләү шартын куярга була. Укучы үз исеменнән, Нурия исеменнән сөйләп карый ала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Нурия нинди кыз? Ул табигатьне күзәтүчәнме? Син табигатьне яратасыңмы? Табигатьтә сине иң сокландырганы нәрсәләр?» һ.б. сораулар ярдәмендә укучыны әңгәмәгә алып кереп, нәтиҗә ясала. Табигать серләре турында күбрәк белергә теләсәң, китаплар укырга кирәклеге турында әйтелә.

Гөлназ һәм Нур әңгәмәсе өстәмә мәгълүмат булып тора. Шул ук вакытта ул әдәби һәм фәнни-популяр текстны танырга булыша. Бу хакта укучылар белән сөйләшеп алу да яхшы.

Касыйм Тәхаунын «Көзге урман» хикәясен укыганчы ук, игътибарлы булу кирәклеге сорала. Укучылар урманда нинди җән-

лекләр, нинди кошлар булуын, аларның кышка ничек әзерләнүләрен хәтерләрендә калдырырга тиеш. Урманда яшәүче җәнлек-кошларның кайсысын бөтенләй белмәүләрен дә ачыклап китү кирәк. (Керпе, тиен, куян, аю, елан, кырмыска, песнәк, кара карганы укучылар тиз таный. Ләтчә, ас, поши, урман тавыгы, кыр үрдәген һәркемнең күргәне булмаска да мөмкин.) Хикәя белән танышкач, бу сорауларны ачыклап бетерәбез. Тактага яки электрон экранга бу җәнлекләрнең рәсемен чыгарып, алар турында кыскача мәгълүмат бирү дә яхшы. Иң элек балалар үзләре белгәннәрне сөйли, укытучы тулыландыра.

**Ирекле аралашу һәрвакыт баланың сөйләм телен баетырга, үстерергә ярдәм итә.**

Хикәя белән танышкач, балалар белән аның әдәби хикәя генә түгел, ә мәгълүмат бирә торган язма икәнен дә ачыклап китү яхшы. Укытучы текст белән эшне үзе теләгән алымнарга нигезләнеп оештыра. Әмма ул яңа, аңлашылмаган сүзләрне үзләштерү һәм хикәянең эчтәлеген дөрес аңлау, анализлауга юнәлтелә. *9 нчы сорау* план нигезендә кыскача эчтәлек сөйләүне сорый. Иң элек *план* сүзен аңлау (аңлату) таләп ителә. Дәреслек ахырындагы «Кулланма ярдәмлек» кыскача эчтәлек сөйләү алгоритмын күрсәтә. Моның өчен кирәкле төп фикерләр планда бирелгәнлеген аңлатабыз. Бирем шул рәвешле үтәлә.

«Сабантуй бүләге»ндәге образлылыкка игътибар итеп, аның нинди җирлектә туганлыгы ачыклана. (Көзнең сарылыгы алтын белән, кышның аклыгы көмеш белән чагыштырыла.)

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәянең («Урман букеты» яки «Көзге урман») эчтәлеген сөйләргә яки, укучыларның үзләренең күзәтүләренә нигезләнеп, көз турында сөйләргә тәкъдим итәргә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Хушлашабыз көз белән (кабатлау).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – көзнең табигать һәм кешеләр тормышына алып килгән үзгәрешләрен, кешеләр һәм табигатьнең үзара бәйләнешен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – алган белемнәрне мөстәкыйль файдалана, тиз эшли алу; нәтиҗә чыгару, гомумиләштерү ясау; үз фикерен әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Алтын көз җитте» бүлегендә өйрәнелгән әсәрләрнең исемен, аларны язган авторларны, әсәрләрнең эчтәлеген, андагы геройларны белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1 .

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

Бу дәрестә укучыларның «Көз» темасына алдагы дәресләрдә ясаган рәсемнәре һәм хикәяләреннән күргәзмә ясарга мөмкин.

## Дәрес барышы

### I. Оештыру-мотивлаштыру.

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

### II. Актуальләштерү.

Укучылардан алдагы дәресләрдә елның кайсы вакыты турында сөйләшүләре, нинди әсәрләр һәм кайсы геройлар хәтерләрендә сакланып калуы хакында сорашырга мөмкин.

### III. Уку мәсьәләсен кую.

Әңгәмә үткәрелә:

– Укучылар, бүгенге дәрестә безнең дусларыбыз күренми. Ни өчен икәнен белмисезме?

– Юк (кемдер үз фикерен башкача әйтергә дә мөмкин).

– Алар бүген Хөрмәтле Дәреслек биргән сорауларга җаваплар әзерлиләр, Хөрмәтле Дәреслеккә алдагы дәресләрдә өйрәнгән «Алтын көз җитте» темасы буенча нәрсәләр белеп калулары турында сөйлиләр. Бу сораулар безнең дәреслегебездә дә бар. Әйдәгез, без дә белемебезне тикшереп карыйк. Никадәр белем тупладык икән? Димәк, без алдагы дәресләрдә үткәннәрне хәтергә төшерәбез, кабатлыйбыз – «Хушлашабыз көз белән».

Арадан иң белемле укучыларны да билгеләрбез. Шуңа күрә һәр сорауга дөрес һәм төгәл җавап бирергә тырышыгыз.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Кабатлау, белемнәрне тикшерүне укытучы төрлечә оештыра ала. Укучыларны төркемнәргә бүлеп тә, яки һәр укучыга сораулар тәкъдим итәргә дә, тактага алмагач куеп, алмаларның алсу ягына сораулар язарга һәм ак ягы белән укучыга каратып ябыштырырга да мөмкин. Укучы алманы ала, сорауны укый һәм җавап бирә. Җавабы дөрес булганда, алманы алсу ягын күрсәтеп элеп куя. Җавабы дөрес булмаса, кире ак ягы белән калдыра. Алсу алмалар никадәр күбрәк булган саен, агачның матурлануына игътибар ителә. Алмаларның хезмәт җимеше икәнлеген әйтеп нәтиҗә ясарга була. Укучыга дөрес җавап өчен яфракчыклар биреп барырга мөмкин. Ул иң күп белүче укучыларны ачыкларга ярдәм итә һәм билге куюны җиңеләйтә.

Дәреслектә кабатлау өчен бирелгән сораулар укучыга укылган әсәрне, аның эчтәлеген, аны язган авторны хәтердә саклау кирәклеген, һәрвакыт истә тоту тиешлеген аңларга булыша. Шулай ук укучы китаптан үзенә кирәкле әсәрне тиз генә таба алуын һәм укылган әсәрләр аша үзләштергән сүз байлыгын куллана белүен дә күрсәтә.

Белемнәрне тикшерү өлешенә нәтиҗә ясаганнан соң, дәреслектәге «Җәй белән Көз очрашканда» хикәясе укыла. Укучылар, хикәягә нигезләнеп, табигатьтәге җәйге һәм көзге үзгәрешләр турында сөйләргә һәм образлылыкка басым ясарга тиеш.

Татар мәктәпләрендә укучыларның хикәя эчтәлеген мөмкин кадәр тулы итеп сөйләп бирә алуларына ирешергә кирәк.

Аерым бүлекне тәмамлаганда, «Минем китапханәм»дә күрсәтелгән китапларга игътибар бирелә, алар укучыларга өстәмә уку өчен тәкъдим ителә.

**V. Өй эше бирү.**

Сыйныфтан тыш уку өчен бирелгән берәр әсәрне укырга.

**VI. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Халык әйтсә, хак әйтә

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – үз халкыңның акылын, тәҗрибәсен мирас буларак кабул итү кирәклеген аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү; иҗади күзаллау, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру, гомумиләштереп нәтиҗә ясау; үз фикерен әйтә белү, башкалар фикерен анализлап кабул итү.

*Предмет нәтиҗәләр* – халык авыз иҗаты, *мәкаль, әйтем* төшенчәләрен үзләштерү, тематик төркемнәрен белү, фольклорның төрле жанрларын аера алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучылар белән алдагы сыйныфларда танышкан халык авыз иҗаты әсәрләре искә төшерелә. Аның әле тагын да төрләре күп булуын искәртеп, китапның 44 нче битендәге рәсем буенча сөйләшү уздырыла. Күбрәк укытучыга сөйләргә туры килер, аңа *халык авыз иҗаты* турында аңлатма бирергә, аның үзенчәлекләрен (телдән телгә күчеп саклануын, бик борынгыдан ук килүен, авторы булмавын, анда халыкның тормыш тәҗрибәсе тупланганлыгын) әйтеп китү кирәк.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслекнең 44 нче битендәге рәсемгә нигезләнеп, укучылар халык авыз иҗатының кайсы жанрлары белән таныш булулары, ә кайсыларын ишетсәләр дә, төгәл генә белеп бетермәүләрен әйтәләр. Димәк, аларны өйрәнәчәкләрен ачыклыйлар. Укытучы бу дәреснең мәкаль һәм әйтемнәрне өйрәнүгә багышланачагын хәбәр итә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Бу этапта дәреслек геройларының әңгәмәсенә таянырга була. Алмаз тәкъдим иткән текст белән танышкач, Нур анда мәкальләр күп булуын искәртә. Аны үзенчә аңлатып та бирә. Укучылар мәкаль турындагы гади аңлатманы иң элек Нурдан ишетә. Алмаз тәкъдиме белән тексттагы мәкаль һәм әйтемнәрне табалар (алар калын хәрефләр белән бирелгән). Укытучы белән бергәләп, аларның мәгънәләре ачыклана. Мәкальләр белән «Сабантуй бүләге»ндә дә танышканлыкларын искә төшерсәләр бик яхшы. Хәтерләрендә сакланган мәкальләре дә булса, бу мактауга лаек.

Алга таба укытучы мәкаль һәм әйтемнәрнең халык сөйләмендә ничек һәм ни өчен (күзәтүдән чыгып ясалган нәтиҗәне баш-

каларга тапшыра) барлыкка килүен, әһәмияте нәрсәдә булуын аңлата. Мәкальләрнең тематик төрлелеге күрсәтелә. Алдагы дәресләрдә бер әйбернең сыйфаты аша икенчене белдерү алымы турында күп тапкырлар сөйләшкәннәр иде. Мәкальләрдә дә без аның белән очрашабыз. Ул гомумиләштереп нәтиҗә ясарга ярдәм итә. Мәкальдә телгә алынган нәрсәләр туры мәгънәдә генә түгел, гомуми фикерне белдерәләр. Китаптагы *чанаңны җәй, арбаңны кыш әзерлә* мәкале шуның ачык мисалы. Мәкаль һәм әйтем турындагы аңлатманы китаптан укып, укучылар тагын бер тапкыр үзләре танышалар.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

47–48 нче битләрдәге рәсемле мәкаль һәм әйтемнәр белән танышу, сорауларга җавап бирү белемне ныгытырга ярдәм итә. 48 нче биттәге буш калган яфракчыкта укучыларга мәкальме яки әйтемме булырга тиешлеген билгеләтергә кирәк. Ул алдагы мисалларга нигезләнеп ачыклана.

**VI. Өй эше бирү.**

Укытучы тәкъдим иткән темага мәкальләр тупларга (5 мәкаль).

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Акылсызга әйтсәң – көлә, зирәккә әйтсәң – белә

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – зирәклеккә, тапкырлыкка, әйдаманлыкка омтылыш уяту.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү; мәгълүмат алу, чагыштыру һәм нәтиҗә ясау, укытучы тәкъдим иткән алгоритмга таянып эш итә белү; үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – фольклорның төрле жанрларын (мәкальләр һәм әйтемнәрне, табышмакларны) аера белү; табышмакларның төзелешен, тематикасын аңлау.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү һәм уку мәсьәләсен кую.**

Алмаз һәм Нур репликасы үткән дәресләрдәге материалны искә төшерергә ярдәм итә. Укучылар бүгенге дәреснең табышмаклар турында икәнен аңлыйлар.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Үткән дәресләрдәге шигырь юлларын искә төшерүнең сәбәбе бар. Ул алдагы дәресләрдә каралган бер әйбердәге сыйфатны аңа охшаш икенче әйберне атау өчен файдалану алымын искә төшерергә ярдәм итә. Табышмаклар барлыкка китерүдә бу алым бик иркен кулланыла: предмет үзенә охшаган башка әйбер аша күрсәтелә. Мәсәлән: алма (*таң төсле, бал төсле*), икмәк (*кояш төсле*), карбыз (*утлы күмер кебек*) һ.б. Алга таба табышмакларның ничек ясалуын аңлатып китү кирәк. Беренче алым – әйбернең исеме әйтелми, ә ул тасвирлап бирелә: 50 нче биттәге *икмәк, чык, карбыз* турындагы табышмаклар моңа мисал була ала. Икенче алым – әйбер үзенә охшаган башка әйбер сыйфаты аша күрсәтелә: 51 нче биттәге *болыт, тукран* турындагы табышмакларны мисал итеп китерергә мөмкин.

Табышмак иҗат итүнең алгоритмы эшләнә.

1. Әйбергә (күренешкә) хас сыйфатлар санала, әмма ул үзе аталмый.
2. Әйбер (күренеш) үзенә охшаш икенче әйбер (күренеш) аша белдерелә.

Болар белән танышкач, табышмакларның халыкта ни өчен барлыкка килүен, тапкырлыкның, зирәклекнең халкыбызда һәрвакыт мактаулы булуын, төрле уен-ярышларда, аулак өйләрдә яшьләрнең табышмак әйтешеп уйнауларын сөйләп китәргә һәм табышмакларның бик борынгыдан кулланылуын, анда халкыбызның тормышы чагылуын аңлатырга була. Китаптагы табышмак турындагы язма белән танышып нәтиҗә ясала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреснең бу өлешендә дәреслектәге табышмаклар һәм сораулар ярдәм итә. Укытучы дәрескә үзе алдан әзерләгән табышмаклар алып килеп, аларның җавапларын табарга яки аерым рәсемнәр биреп, андагы әйбер (күренеш) турында табышмак иҗат итәргә куша.

Татар мәктәпләре өчен Сара тәкъдим иткән табышмаклы уен үткәрелә.

**VI. Өй эше бирү.**

Табышмак уйлап табарга һәм җавабын рәсем итеп ясарга. (Кәгазьнең бер ягына табышмак языла, икенче ягына рәсем-җавап ясала, бу – икенче дәрестә уен оештыруга ярдәм була.)

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** И ямьле дә соң дөнья!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – туган җир матурлыгын күрә, башкалар белән уртаклаша белү; кешеләрнең күңелләре матур булганда гына дөнья ямле икәнлеген аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү; иҗади күзаллау, күзәтүчәнлек, чагыштыру, сәбәп-нәтиҗә бәйләнеш-

ләрен табу һәм нәтиҗә ясау; башкалар фикерен ишетү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Ләбиб Леронның «И ямьле дә соң бу дөнья!» хикәясе эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Көзге табигать турында алдагы дәрестәге белемнәргә нигезләнеп, сөйләшү үткәрергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек геройларының әңгәмәсе ярдәмендә укытучы «Кайсы ел фасылы иң матуры?» дигән сорау куя ала. Бу сорауга укучыларның җаваплары тыңлана.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Ләбиб Леронның дәреслектәге «И ямьле дә соң бу дөнья!» хикәясе белән танышуга күчелә. Хикәяне сәнгатьле итеп укытучы укый, яки аудиоязмада тыңларга мөмкин. Видеодәрес материалыннан да файдаланып була. Хикәяне уку, сүзлек белән эш һәм сорауларга җавап бирүне укытучы сыйныфтагы укучыларның белемнәре нинди булуына, алга куелган максатына яраклаштыра. *3 нче сорауга* җавап биргәндә, мөмкин кадәр сөйләм матурлыгына игътибар иттерү яхшы. Һәр ел фасылы турындагы өлешне аерым укып, эчтәлеген сөйләтеп барганда, *5 нче сорауга* җавап бирү күпкә җиңел

биреләчәк. *4 нче сорауга* җавап алганда, кояш, җил, сентябрьнең җанлы затларга охшатып сурәтләнүе тагын бер тапкыр искәртелә. Язучы кояшны Кояшсылу дип атый, шуның белән ул аны назлы, җылы, сөйкемлелеге белән җәлеп итә торган гүзәл зат – хатын-кыз белән тиңләштерә. Сентябрь һәм Җилне шуклыклары, тиктормас һәм шаян булулары сәбәпле малай дип атый.

*6 нчы сорауның* җавабы үз эчендә үк бар. Хикәя ике өлешкә бүленә. Әмма әлеге өлешләрнең аермасын һәм охшашлыгын табу яхшы булыр. Аермасы – беренче өлеш табигать, икенчесе кешеләр тормышы турында. Охшашлыгы – дөнья матур. Ике өлешне дә матурлык бәйләп тора. *7 нче сорауга* укучылар дөрес җавап бирсен өчен, укытучының ярдәме кирәк булыр.

**Дөнья матурлыгы кешеләрнең күңелләре матурлыгыннан туа.**

Татар мәктәпләрендә Ләбиб Леронның «Соклангыч дөнья» шигыре дә укыла. Ул хикәя белән чагыштырыла.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Һәр ел фасылы үзенчә матур. Дөнья янәшәңдә син яраткан, сине яраткан кешеләр булганда, һәр кеше үзен бәхетле санаганда гына матур.

**VI. Өй эше бирү.**

Китапның 59 нчы битендәге рәсемгә нигезләнеп, хикәянең эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Балачак иле – зәңгәр ил

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – балачак хыяллары киләчәкнең юл башы икәнен, бәхетле илдә генә балачак та бәхетле була алганлыгын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Рәдиф Гаташның «Зәңгәр ил – балачак иле» шигыренең эчтәлеген аңлау, аның нигезендә сорауларга җавап бирү; шигырьнең темасын һәм төп фикерен билгеләү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Укучылар белән исәнләшү, дәрескә әзерлекләрен сораштыру.

Дәрескә оештыру.

**II. Актуальләштерү.**

Л. Леронның «И ямьле дә соң дөнья!» әсәренә нигезләнеп, балачак хыяллары, бала вакытның рәхәтлеге турында сөйләшү үткәрергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек геройларының әңгәмәсе дәреснең темасын ачыкларга ярдәм итә. Балачак иле – хыяллар иле, һәркем хыялланырга ярата. «Туган җир һәм балалык хыяллары бер-берсеннән аерылгысыз» дигән фикерләр укучыга бу дәресебез балачак хыяллары һәм Туган җир турында булуын әйтеп бирергә ярдәм итә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

**Укытучыга.** Дәреснең темасы: Балачак иле – зәңгәр ил. Бу – шигырь исеменә бәйләнешле. Укучыга теманы ачарга ярдәм итү өчен, татар телендә *зәңгәр* сүзенең мәгънәсенә игътибар итү кирәк. *Зәңгәр* сүзе *зәңгәр һава, зәңгәр су, зәңгәр томан* сүзтезмәләре барлыкка китереп, чиксезлекне белдерә. Аңлатмалы

сүзлектә *зәңгәр* сүзенең күчерелмә мәгънәсе ике мисал ярдәмендә аңлатыла. Беренчесе – тормышка зәңгәр күзлек аша карау – кешене һәм тормышның барлык якларын да идеаллаштыру, кимчелек күрмәү, җитешсезлекләргә игътибар итмәү. Икенчесе – зәңгәр хыял – тормышка ашмаслык хыял.

Рәдиф Гаташның (Гатауллин) «Зәңгәр ил – балачак иле» шигыре менә шушы ике мәгънәне берләштерә. Бала өчен тормышның кимчелекләре юк, хыяллар да гаять зурдан, тормышка ашмаслык дәрәҗәдә була. Ләкин кешегә үскән саен тормышның катлаулылыгын тирәнрәк аңларга, аның кырыс чынбарлыгы белән ныграк көрәшергә туры килсә дә, ул балачак иленнән алган рухи сафлык, тормышка ашмас хыяллар биргән этәргеч белән алга хәрәкәт итә. Балачак биргән бәхетле мизгелләр кешене бөтен гомере буена алга ашкындыра, көч бирә.

Ә балачакның нинди булуы, күңелдә нинди хыял-омтылышлар тудыруы турыдан-туры җәмгыять, ил, илнең икътисади һәм сәяси кыйбласы белән бәйле. Шагыйрь әйтергә теләгән фикер шуңа кайтып кала.

Икенче сыйныф укучысына моны гади сүз белән ничек аңлатырга? Иң элек шигырь белән, сүзлек белән танышу кирәк. Алга таба шигырьне ике өлешкә бүләргә кирәклеген күрсәтәбез. Беренче өлештә без яши торган Туган ил, Ватан турында (шигырьнең беренче биш юлы һәм *Татулык, Дуслык Туганлык, ... Зәңгәр күкле Туган илем* дип тәмамланган куплет). Ул – чынбарлык. Икенче ил – Балачак иле – хыялдагы ил. Зәңгәр ил – кимчелекләрсез тормыш, ул – чынга ашмас хыяллар дөньясы, киләчәккә әйдәүче җыр. Әлеге бүленешне ачыкларга дәреслектәге сораулар булыша. Әмма шигырьнең хисләр тезмәсе һәм образлардан торуы укытучы ярдәмен таләп итә. Максатка ирешү өчен, укучыны дәрес рәсмилегеннән аерып, үзенең хыял дөньясы, балалык эчкерсезлеге белән кушылуына ирешергә, лирик герой хисләре дулкынына күчәргә ярдәм итәргә кирәк.

Рәдиф Гаташның «Зәңгәр ил – балачак иле» шигырен өйрәнгәндә, аудиоязмадан тыңларга, яки видеодәрес материалыннан да файдаланырга була.

«Ни өчен шагыйрь балачак илен зәңгәр ил дип атый икән соң?» дигән сорау куеп, зәңгәр төснең чиксезлек, сафлык, су, күк йөзе белән бәйлелектә күзаллануын искәртергә була.

Татар мәктәпләре бу хакта әңгәмәне дәвам итә. Моңа дәреслек тәкъдим иткән хикәя ярдәмгә киләчәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Синең балачагың нинди? Образлы итеп сурәтләп кара. Сине әйләндереп алган шатлыклы мизгелләрне, уенчыкларны, дусларың, гаиләң белән үткәргән ял вакытларын, тирә-якның матурлыгын, иң якын кешеләреңне исеңә төшер», кебек фикерләр белән укучыны шигырь тудырган кичерешләргә якынайтырга, аның эченә алып керергә кирәк. Шул җирлектә алар шигырьдәге балачак иленең матурлыгын аңлый алачак. «Ә безнең Туган илебез нинди? Ул шигырьдә сурәтләнгән илгә охшаганмы?» кебек сораулар Туган илебезнең *Дуслык,Туганлык, ... Уңганлык* (хезмәт сөючән кешеләр яши торган) иле икәнен дәлилләргә булыша.

Бәхетле илдә яшәгәндә генә, балачак бәхетле була, дигән нәтиҗә ясала.

Шигырьдә *байрак* сүзе илнең йөзен, асылын билгели торган иҗтимагый-сәяси кыйбласын аңлата.

**VI. Өй эше бирү.**

Рәдиф Гаташның «Зәңгәр ил – балачак иле» шигырен сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Эш беткәч уйнарга ярый

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – укуның зур ихтыяр көче сорый торган әһәмиятле хезмәт булуын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иҗади күзаллау; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру һәм нәтиҗә ясау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Габдулла Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый» шигыренең эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирә белү; укылган әсәрнең эчтәлеге турында сораулар әзерли алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1.

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәресләрдә балачакның матур хыялларга бай, бик рәхәт вакыт булуы турында сөйләшүне дәвам итәргә мөмкин. «Бу яшьтә мөһим, кичектермәслек бурычлар, эшләр дә буламы соң?» дигән сорау ярдәмендә алдагы этапка күчелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек геройлары әңгәмәсе уку мәсьәләсен ачыкларга ярдәм итә. «Безнең төп эшебез – уку», – дип белдерә Сара. Укучылар, шул фикергә нигезләнеп, укуның иң мөһим эш икәнлеге турында сөйләшәчәкләрен әйтәләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Габдулла Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый» шигырен уку, сүзлек белән эш һәм сорауларга җавап бирүне укытучы сыйныфтагы укучыларның мөмкинлегеннән чыгып оештыра, ул

вакыт ягыннан да төрле була. База программасын үзләштерүчеләргә авыррак икәнлеген истә тотып, дәреслектәге сораулар беркадәр җиңелрәк итеп эшләнде. *Беренче сорауда:* «Шигырьнең исеме сиңа танышмы?» – дип сорала. Укучы аның белән мәкальләр темасында танышканлыгын яки аның мәкальгә охшашлыгын тоемларга тиеш. Бу очракта укытучы ярдәме кирәк булырга мөмкин.

Татар мәктәпләре программасында әдәби төшенчә – *сынландыру* өйрәнелә. Бу дәрескә кадәр аның мисаллары белән күп тапкырлар очрашканлыктан, аны аңлау укучылар өчен авырлык тудырмас. Бары шигырьдәге мисаллар ярдәмендә ныгытырга туры киләчәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Габдулла Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый» шигыренең эчтәлегенә нигезләнеп, укуның тырышлык таләп итә торган хезмәт икәнлеге турында әңгәмә үткәрү. Кеше өчен ихтыяр көче булдыруның әһәмияте турында сөйләшү.

Габдулла Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый» шигыренең героен характерлап бирү, аның эш-гамәлләрен бәяләү.

**VI. Өй эше бирү.**

Габдулла Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый» шигырен ятларга (67–68 нче битләрдәге өлешне). (Теләгән, мөмкинлеге булган укучы шигырьне тулысынча ятлый ала.)

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Соклангыч дөнья (кабатлау).

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – яхшы эшләр, кешеләрнең күңел матурлыгы дөньяны сокланырлык матур итүен, моңа һәркем үзеннән өлеш кертә алуын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – алган белемнәрне мөстәкыйль файдалана, тиз эшли алу; нәтиҗәләр формалаштыру, гомумиләштерү ясау; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә белү, тәкъдим ителгән үрнәкләргә таянып, күмәк проект биремнәрен үтәү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «И ямьле дә соң дөнья!» бүлегендә өйрәнелгән әсәрләрнең исемен, аларны язган авторларны, әсәрләрнең эчтәлеген, андагы геройларны белү.

*Материал:* Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1.

Җиһазлау: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дәреснең бу өлеше укучылар ятлаган шигырьләрне тыңлау белән узачак.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укытучы бу дәреснең алда үтелгән «И ямьле дә соң дөнья!» темасын ныгыту дәресе булачагын белдерә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Укучылар дәреслекнең 73 нче битендәге сорауларга җаваплар бирергә тиеш. Бу эшне укытучы үзе теләгән формада оештыра.

Сорауларга җавап биргәннән соң, Җәвад Тәрҗемановның «Чирик» хикәясен укып сорауларга җаваплар бирелә. Тормыш белән бәйләп әңгәмә үткәрелә. Хикәя тормышны яхшы гамәлләр матурлый дигән нәтиҗәгә алып чыга. Укучыларның күңелендә шул урнашып калсын иде.

«Дөнья ни өчен сокландыргыч?» дигән сорауга җавап табу. Укучылар фикерен тыңлау.

Аерым бүлекне тәмамлаганда, «Минем китапханәм»дә күрсәтелгән китапларга игътибар бирелә, алар укучыларга өстәмә уку өчен тәкъдим ителә.

**V. Өй эше бирү.**

«Мин яшәгән дөнья» темасына проект эше эшләргә кушыла. Аны үтәү тәртибе аңлатыла.

**VI. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Кышкы кунак

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигатьне саклый, аңа ярдәм итә һәм матурлыгын күреп соклана белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, фаразлау, фаразны нәтиҗә белән чагыштыру; мәгълүмат алу, тамга-символик чараларны куллану, үз фикерен дәлилли белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Абдулла Алишның «Январь» хикәясенең эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирә белү, хикәянең темасын билгеләү. Татар мәктәпләрендә Гамил Афзалның «Беренче кар» шигыренең дә эчтәлеген аңлау һәм сорауларга җавап бирү.

**Материал**: Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part2/.

**Җиһазлау**: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Кышкы табигать, балаларның тирә-якны күзәтүләренә нигезләнеп, сөйләшү үткәрергә, укучыларны тыңларга мөмкин. Әлеге әңгәмәгә дәреслек геройларының диалогы да кушылып китә ала.

Ажаганны табигатьнең матур бер күренеше буларак хәтердә калдыралар.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең бу этабында дәреслекнең 7 нче битендәге рәсем ярдәм итә. Укучылар әлеге рәсемдә нәрсә һәм кемнәр сурәтләнүен фаразлап сөйләп бирәләр. Укылачак хикәянең дә нәрсә турында булуын әйтеп карыйлар. Хикәянең исеме – «Январь». Аның ни өчен шулай аталуын да күзалларга мөмкин.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

А. Алишның «Январь» хикәясен видеодәресне кулланып өйрәнергә була. Хикәя белән танышкач, укучылар үзләренең фаразларының никадәр төгәл булуын ачыклыйлар. Бу хикәя рольләргә бүлеп уку өчен дә уңай. Сүзлек белән эш һәм сорауларга җавап бирүне укытучы үз эзлеклелегендә оештыра. 1–5 нче сораулар укучының хикәя эчтәлегенә дә, табигатькә һәм әйләнә-тирә мохиткә игътибарлылыгын ачыкларга ярдәм итә.

Дәрестә вакыт ягыннан мөмкинлек булганда, эчтәлек сөйләү, хикәя эчтәлегенә нигезләнеп сорау бирү кебек эш формаларын файдалану яхшы. Эчтәлек сөйләгәндә, кем исеменнән сөйләүгә игътибар иттерү һәм төрле формаларын куллану да кирәк. Балалар үзләре исеменнән дә сөйләргә өйрәнергә тиеш. Мәсәлән, хикәядәгечә: «Январь **безгә** шундый ияләште», – дип түгел, ә «Январь **аларга** шундый ияләшә».

6–9 нчы сораулар укучыларны ирекле әңгәмәгә чыгара.

Алга таба Гамил Афзалның «Беренче кар» шигыре белән эш оештырыла.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Хикәя эчтәлеген истә калдырырлык сораулар белән дәрестә өйрәнгәнне хәтердә ныгыткач, табигатьне саклау, шәфкатьлелек турындагы фикерләр дә ассызыклана.

Дәрескә йомгак ясарга «Сабантуй бүләге» ярдәм итә: *яхшылык җирдә ятмый.* ( Никадәр яхшы була алсаң, үзеңә дә ул шулкадәр үк яхшылык булып кайта.) Хикәя эчтәлегеннән чыгып, кеше табигатьне саклап, аңа ярдәм итеп яшәгәндә, табигатьнең дә кешене матурлыгы, байлыгы һәм муллыгы белән сөендерүен әйтергә кирәк.

Сүзлектәге авыррак сүзләргә (*үрле-кырлы, имгәнгән, ияләшү – күнегү*) кайтып, аларны хәтердә калдыру өстендә эшләргә була.

Беренче кар яуганны күргәнең бармы? Шул көнге истәлекләреңне белән уртаклаш.

**VI. Өй эше бирү.**

Абдулла Алишның «Январь» хикәясенең эчтәлегенә карата сораулар уйларга яки хикәянең эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Кыш һәм кеше

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – хезмәтнең кеше тормышындагы әһәмиятен аңлау, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру, нәтиҗәләр формалаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Бари Рәхмәтнең «Кыш һәм кеше» шигыренең эчтәлеген аңлау, аның ярдәмендә сорауларга җавап бирә белү.

**Материал**: Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part2/.

**Җиһазлау**: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәресләрдәге кыш турындагы сөйләшүне дәвам итеп, укучыларның кышны яратулары, көтеп алулары яки, киресенчә, кышның суыклыгыннан куркулары турында сораулар биреп, сөйләшү үткәрергә була. Бу очракта дәреслек геройларының әңгәмәсенә нигезләнергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслекнең 14 нче битендәге рәсем бу дәрестә уку мәсьәләсен куярга ярдәм итә ала. Рәсемнең һәр деталенә игътибар иткәндә, кышның усалланып салкын өрүе, ә кешенең бүрек, бияләйләрен салып эшләвен күреп, «Ни өчен кеше кышкы суыкта туңмый?» дигән сорау куела һәм аңа җавап эзләүгә күчелә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Бари Рәхмәтнең «Кыш һәм кеше» шигырен сәнгатьле итеп укытучы укый яки аудиоязмада тыңларга була. Бари Рәхмәтнең «Кыш һәм кеше» шигыре белән танышканда, аны мәгънә үзгәреше ягыннан өлешләргә бүлеп укып, һәр өлешнең эчтәлеге турындагы сорауларга җавап биреп барырга мөмкин. 1–4 нче дүртьюллыклар кышны сыйфатлый. *Агач кисәргә тотына кеше, Кисешә бергә аның күршесе* дигән юллар кешеләрнең бердәмлеген күрсәтә. Алдагы өлеш кыш һәм кеше арасындагы әңгәмә турында. Бу юлларда кешенең кәефе нинди булуын билгеләп үтү яхшы. Ахыргы дүртьюллык-нәтиҗә: эш белән дус булганга кеше кышка бирешми. Сүзлек белән эш үткәргәч, текстны сәнгатьле итеп укуны да төрлечә оештырырга мөмкин. Рольләргә бүлеп уку алдагы сорауларга җавап биргәндә ярдәм итә ала (5, 6 нчы сораулар өчен).

Сорауларга җавап өлеше дәреснең төп соравына җавап табарга булыша.

Алга таба кабат дәреслектәге рәсемгә әйләнеп кайтып, рәссам кышны ничек итеп ясаганлыгын ачыклыйбыз (ул аны кешегә охшаткан). «Шигырьдә Кыш ничек кешеләштерелә, ул кешегә хас нинди сыйфатларга ия?» дигән сорау ярдәмендә образлылык тагын бер кат укучылар күңелендә яңартыла.

Татар мәктәбендә Мәхмүт Хәсәновның «Көн җылынды» хикәясе укыла.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Шигырь һәм хикәя эчтәлегенә кагылышлы сорауларга җавап алына. Кеше тормышында бердәмлек һәм хезмәтнең төп кыйммәт икәнен аңлатып нәтиҗә ясарга «Сабантуй бүләге» ярдәмгә килә. *Хезмәтнең тире ачы, җимеше татлы.* (*Хезмәт үзе авыр булып, тырышлык, тир түгү таләп итсә дә, нәтиҗәсе һәрвакыт сөенечле, файдалы була.*) Шигырьдәге фикер белән хикәядәге (М. Хәсәнов. «Көн җылынды») фикерне чагыштырып, гомуми нәтиҗә ясала.

Укучыларның мөмкинлегеннән чыгып, өстәмә материалны база белеме алучыларга да тәкъдим итеп була.

**VI. Өй эше бирү.**

Бари Рәхмәтнең «Кыш һәм кеше» шигырен сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Чыршы янында

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – бәйрәмнәр рухы тудыруга өлеш кертүнең әһәмиятен аңлау һәм бүләк бирү, бүләк алу әдәпләрен белү; үз кулың белән бүләк әзерләү – хезмәтне яратырга өйрәнү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Сәхаб Урайскийның «Чыршы янында» шигыренең һәм Аяз Хәсәннең «Кыш бабай бүләк өләшә» хикәясенең эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал**: Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part2/ .

**Җиһазлау**: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Кыш турында сөйләшүнең дәвамы буларак, кышның нинди бәйрәм белән күңелгә кереп калуы хәтергә төшерелә. Дәреслек геройларының әңгәмәсенә кушылып, укучылар үзләренең бу бәйрәмгә ничек әзерләнүләре турында сөйли.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Сәхаб Урайский сүзләренә И. Шәмсетдинов язган «Чыршы янында» җырын яки башка берәр Чыршы бәйрәме турындагы җырны тыңлау ярдәм итә. (Әгәр укучылар бу җырны белсә, бергәләп җырлау тагын да нәтиҗәлерәк.) Укытучы бу бәйрәмнең тарихы турында әйтеп үтә ала.

*Беренче тапкыр Яңа елны январьдан башлау һәм аны бәйрәм итү турында Указны 1669 елда Петр I чыгара. 1700 ел январь аеннан башлана (элегрәк ул башта март, аннары сентябрь айларыннан башлана торган булган). Петр I урамнарны яшел чыршы, нарат ботаклары белән бизәтә, беренче салютны да ул куллана. XIX гасырның башында өй эчендә чыршы бизәү башлана, шул ук гасыр уртасында зур залларда чыршы бизәп бәйрәм үткәрү гамәлгә куела. Революциядән соң бу бәйрәм искелек буларак туктатыла, кабат 1935 елда гына кайтарыла (чыршы бизәп, Яңа ел бәйрәме үткәрү). 1937 елда бәйрәмгә Кыш бабай янында Кар кызы да килә башлый. 1938 елда зур чыршы Кремль залында бизәлә, бәйрәм үткәрелә.*

*Чыршы бизәү бу агачның гел яшел булуы белән бәйле. Ул ныклык, үлемсезлек символы буларак кабул ителә. Агачларны күпләп әрәм итмәс өчен, ясалма чыршылар булдырыла.*

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Сәхаб Урайскийның «Чыршы янында» шигыре белән танышкач, дәреслектәге сорауларга җавап бирелә. Шигырьдәге фикерне дәвам итеп, укучылар үзләре күргән яңа ел чыршылары, аларның ничек бизәлүе турында сөйли алалар. Урамда, паркларда, өйдә, мәктәптә бизәлгән чыршыларны чагыштырырга мөмкин. Укытучы төрле еллардагы чыршы уенчыкларының нинди булуын күрсәтеп тә әңгәмә үткәрә ала. Баланың мөмкин кадәр әлеге

темага якынаюы, сөйләшүгә кушылуына ирешергә генә кирәк. Укучы ирекле аралашуга күчәрлек мохит тудыру бик мөһим. Дәреслекнең 19 нчы битендәге рәсем әңгәмәне дәвам итәргә һәм бүләкләр темасына күчеш ясарга булыша. Дәреслек геройларының әңгәмәсе белән танышу бүләкләшү әдәбен аңларга ярдәм итәчәк. «Сабантуй» бүләге нәтиҗәне ныгытып куя.

Татар мәктәпләрендә Аяз Хәсәннең «Кыш бабай бүләк өләшә» хикәясе өйрәнелә. Хикәягә күчеш өчен дәреслек геройларының әңгәмәсе булыша. «Сабантуй бүләге» ярдәмендә хикәягә нәтиҗә ясала. Мактанчыклык, үзеңне башкалардан өстен күрү кебек сыйфатларның начар булуы аңлатыла, киң күңеллелекнең күркәм сыйфат булуы күрсәтелә (Куян һәм башкалар мисалында).

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Яңа ел бәйрәмен Чыршы бәйрәме дип тә атыйлар. Ни өчен икән? Шигырьдәге чыршы нинди?» һәм башка сораулар белән укучыларның текстны аңлавы, үзләштерүе тикшерелә. Шигырьне ятлыйсы булуын истә тотып, аны берничә тапкыр дөрес, сәнгатьле итеп укыту да файдалы.

**VI. Өй эше бирү.**

Сәхаб Урайскийның «Чыршы янында» шигырен ятларга (теләге булган укучы җырлап күрсәтә ала).

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Кышкы урман

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигатьнең һәр фасылының үзенчә матур булуын аңлау, аны күзәтергә, аның белән хозурланырга өйрәнү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иҗади күзаллау; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу һәм нәтиҗә ясау; башкалар фикерен аңлап кабул итү, үз фикерен әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Әмирхан Еникинең «Кышкы урман» хикәясенең һәм Әнәс Каринның «Кошлар туйдырам» шигыренең эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал**: Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Мөхәрләмова Г.Н. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part2/.

**Җиһазлау**: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәресләрдәге Яңа ел бәйрәме, Кар кызы, Кыш бабай турындагы әңгәмәне дәвам итеп, кыш матур, бәйрәмнәре белән тагын да ямьле, дип нәтиҗә ясарлык сөйләшү үткәрергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек геройларының кышкы матурлык турындагы әңгәмәсенә нигезләнеп: «Ә кышкы урман нинди була икән? Беләсегез киләме? Сезнең анда булганыгыз бармы? Ничек күз алдына китерәсез?» кебек сорауларга җавап табу дәрес темасын билгеләргә мөмкинлек тудыра. Шулай ук кышкы урманны сурәтләгән рәсем яки шигырь дә ярдәм итә ала.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Хикәяне укуга аның авторына игътибар итеп, Әмирхан Еникинең бик тә матур телле язучы икәнен, алда әле укучыларның бу авторның күп әсәрләре белән танышачакларын да искәртеп үтү

яхшы. Сүзлек белән эш образлы сүзләрнең кулланылыш ешлыгын да аңларга ярдәм итә. Автор бер дә гади генә сүзләр кулланмый икән бит. *Тынлык* турында гына да никадәр төсмер: *тын, шундый тын, ник бер җан әсәре сизелсен, ник бер шылт иткән тавыш ишетелсен, кычкырсаң да тавыш китә, югала (тынлыкны бозу мөмкин түгел), куе тынлык урнаша; бер генә нәрсә дә кузгалмый, селкенми; урман сине ишетергә дә, белергә дә теләми.* Шуларның һәммәсен бергә җыеп, автор *өлкән тынлык* дип исем бирә. *Серле, аңлавы да читен* дип бәяли. Билгеле, укучылар моның һәммәсен дә таба алмый, укытучы ярдәме кирәк. Укучы иң элек күрсәткәнне аңлап кабул итәргә өйрәнә. Бу – дәвамлы эш. Бер дәреслек, хәтта бер еллык кына да түгел. Шуңа телнең матурлыгына, сурәтләү чараларына һәрвакыт игътибар бирү зарур.

Сорауларга җавап тапканда, укучы бу бизәкләргә тагын бер кат әйләнеп кайта. Хикәяләүченең үзенчәлегенә дә игътибар итәбез. *Аталы-уллы урманга бардылар* җөмләсе кышкы урман матурлыгын күзәтүчеләрнең ике кеше икәнлеген ача. Ә кем хикәяли: этисеме, улымы? Аларның икесе исеменнән автор-хикәяләүче сөйли кебек кабул ителә. Моңа да игътибар юнәлтү яхшы.

8 нче сорау хикәянең образлылыгын тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

«Сабантуй бүләге» Касыйм Тәхауның «Кышның соңгы ае» язмасы белән танышуга күпер сала. Киресенчә, мәкальгә язманы укыганнан соң кайтырга мөмкин. «Кышкы урман» хикәясе белән чагыштыру уздырырга була. Касыйм Тәхауның «Кышның соңгы ае» мәгълүмат бирүне максат итә. «Кышкы урман» хикәясе образлы сурәт тудыра: ул – әдәби әсәр, образлылыкка өстенлек бирә. Укучылар бу аерманы тоемларга өйрәнсә яхшы була.

Татар мәктәпләрендә Әнәс Каринның «Кошлар туйдырам» шигыре дә өйрәнелә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучыларның хикәянең эчтәлеген, образлылыгын аңлауларын тикшерә алырлык сораулары белән дәрес материалы ныгытыла. Максат – укучының хикәянең эчтәлеген төгәлрәк бирә алуына

ирешү. Вакыйга күчеше күзәтелмәгән, мизгелне тәфсилле тасвир ярдәмендә сурәтләгән өзекнең эчтәлеген сөйли белү. Бу киләчәктә пейзаж бирелешен аңлауга юл ачарга тиеш.

«Ни өчен кышын кошларга җимлек куярга кирәк? Җимлеккә нәрсәләр салырга була?» кебек сораулар бирергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәядәге сүзләрне кулланып, кышкы урман матурлыгы турында сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Кышкы бизәкләр (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – кышның табигать һәм кешеләр тормышына алып килгән үзгәрешләрен аңлау; матурлыкка соклана, табигатьне ярата һәм саклый белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен кую, алган белемнәрне мөстәкыйль файдалана, тиз эшли алу, бәяләү; нәтиҗәләр формалаштыру, гомумиләштерү ясау; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Ап-ак кыш килде» бүлегендә өйрәнелгән әсәрләрнең исемен, аларны язган авторларны, әсәрләрнең эчтәлеген, андагы геройларны белү, Константин Ушинскийның «Дүрт теләк» хикәясенең эчтәлеген, темасын (нәрсә турында булуын) аңлау һәм әйтеп бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1 .

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, биремле конвертлар.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Кышкы күренеш тасвирланган рәсемгә нигезләнеп, сөйләшү үткәрергә мөмкин. Кышкы табигатькә хас билгеләрне санау төрле сорауларга җавап бирү, сөйләм телен баетуга ярдәм итә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Без бу дәрестә кыш турында укыган барлык әсәрләрне искә төшерәбез, белемнәрне ныгытабыз. «Дәресебезнең темасы ничек булыр? Кем әйтә ала?» дигән сорауга укучыларның җавапларын тыңлагач, укытучы, бу җавапларны бергә җыеп, дәреснең темасын матур исем белән «Кыш бизәкләре» дип атарга чакыра.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

– Ә кышның төп бизәге нәрсә соң, укучылар? – дип сорыйбыз.

Әйе, кышның төп бизәге – кар. Менә минем өстәлемдә бик матур кар бөртекләре ята. Дәрес барышында мин аларны сезгә бирәм, ләкин бер шарт белән: сорауга дөрес җавап биргән укучы кыш бизәге – кар бөртеге белән бүләкләнә. Кемнең кар бөртеге күбрәк, ул сыйныфта «Иң күп белүче» дигән исемгә лаек була.

Укытучы «Ап-ак кыш килде» темасы буенча әзерләп килгән биремнәр белән эшли. Һәр дөрес җавап бер кар бөртеге белән бәяләп барыла. Биремнәр төрлечә булырга мөмкин. Анда дәреслекнең 33 нче битендәге сорауларны да кулланырга була. Дәрестә барлык укучыларның да тигез катнашуын тәэмин итү өчен, карточкалар эшләп, һәр укучыга өләшергә, тизлеге түбән булганнарга шәхсән сораулар биреп, җавапларын көтеп алырга да туры килергә мөмкин. Дәрестә һәр укучының берничә кар бөртеге җыюына ирешергә кирәк. Аерым сорауларны слайд рәвешендә тәкъдим иткәндә дә яхшы. Сораулар төренә әсәрдән бирелгән

өзекне белү, әсәрнең героен танып алу яки герой аша әсәр исемен ачыклау һ.б. төр сораулар тәкъдим итәргә була.

Укучылар, җыелган кар бөртекләренә карап, үзләренә бәя бирәләр. Дәрес ахырында кар бөртекләрен санап нәтиҗә ясала. Кар бөртекләрен тактага тау рәвешендә ябыштырып, «Белем тавы» булдырыла.

Алдагы этапта Константин Ушинскийның «Дүрт теләк» хикәясе укыла. Дәреслектәге сорауларга җаваплар алынып, укучыларның Митя фикеренә булган мөнәсәбәтен тыңлаганнан соң, бергә нәтиҗә ясала.

Аерым бүлекне тәмамлаганда, «Минем китапханәм»дә күрсәтелгән китапларга игътибар бирелә, алар укучыларга өстәмә уку өчен тәкъдим ителә.

**V. Өй эше бирү.**

Сыйныфтан тыш уку өчен бирелгән берәр әсәрне укырга.

**VI. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Туган тел

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – туган телеңне белү, аны гомерең буена кадерләп саклау; мәгълүмат алу, тамга-символик чараларны куллану; буыннан-буынга тапшыру һәркем өчен изге бурыч икәнен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, укылган текстны тормыш белән бәйли алу, башкалар фикерен кабул итә, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Габдулла Тукайның «Туган тел» шигыренең эчтәлеген аңлау, аның нигезендә сорауларга җавап бирә белү; укылган текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part2/.

**Җиһазлау**: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дәрес башында баланың, бишек җыры тыңлап, кечкенәдән ишетеп үскән әкиятләрен, туган йорт җылысының, сабыйлыкның рәхәтлеген күңелендә яңартырга мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Уку мәсьәләсен куярга дәреслек геройларының әңгәмәсе һәм «Өч угыл» әкияте булышыр. Шулай ук дәреслекнең 40 нчы битендәге рәсемне дә файдаланырга була. Шулар ярдәмендә укучылар, бу дәрестә туган тел турында сөйләшәчәкбез, дигән фикергә килә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреслекнең 40 нчы битендә Алмаз һәм Гөлназ репликасы Габдулла Тукайның «Туган тел» шигыренә күчүгә мөмкинлек тудыра. Шигырьне өйрәнү укытучы теләгән эзлеклелектә оештырыла. Ул әсәрне уку, тыңлау, сүзлек белән эш һәм сорауларга җавап бирү этапларын үз эченә ала. Әмма *туган тел* төшенчәсен хәзерге буын балаларына аңлатканда, бик әһәмиятле бер үзенчәлек бар. Шигырьдә туган тел – әткә-әнкә, әби-баба теле. Ә укучыларның ата-анасы, әби-бабасы татар телендә сөйләшми торган татарлар булганда, бу мәсьәлә бөтенләй башкача хәл ителә бит

(ә Г. Тукай иҗат иткән чорда андый каршылык булмаган). Әлеге очракны күз уңыннан ычкындырмыйча, укытучы туган телнең милли тел, халкыбыз теле булуын, халкыбызның нинди сыйфатларга ия икәнлеген икенче сыйныф укучысы да төшенерлек итеп аңлатылырга тиеш. Дәрес башында тыңланган бишек җырының моңы, укучылар укыган әкиятләрдәге гаделлек һәм намуслылык, ярдәмчеллек, халкыбызның матур бәйрәмнәре һ.б. әлеге максатка хезмәт итә ала.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Г. Тукайның шигырендәге туган телне тасвирлаган гыйбарәләрне, «Өч угыл» әкиятенең төп фикерен, халкыбызның туган тел турындагы мәкальләрен искә төшерү дәрес темасының төп эчтәлеген хәтердә калдырырга ярдәм итәчәк.

**VI. Өй эше бирү.**

Габдулла Тукайның «Туган тел» шигырен ятларга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Безнең ил – бәхет иле

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – Туган илебезнең бай, көчле һәм искиткеч матур зур Россия икәнен аңлау. Туган ил, Ватан, туган җир белән горурлану. Аның турында күбрәк белергә теләк уяну.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Әхмәт Рәшитовның «Кояшлы ил – бәхет иле» шигыренең һәм Энҗе Мөэминованың «Туган телем» шигыренең эчтәлеген аңлау, әсәр буенча сорауларга җавап бирә белү, шигырьләрнең темасын һәм төп фикерен билгели алу.

**Материал**: Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part2/.

**Җиһазлау**: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, Россиянең һәм Татарстанның физик картасы.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучылар белән Туган ил, туган тел турында белгән мәкальләрне искә төшереп, алдагы дәрестә Туган ил турындагы сөйләшүне дәвам итеп, уртак фикергә килү.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслектәге Нур һәм Алмаз репликасы белән танышу уку мәсьәләсен куярга булыша. Укучыларга: «Игътибар иттегезме, Нур белән Алмаз нәрсә турында сөйләшә?» дигән сорау ярдәмендә укучылардан бу дәрестә Туган ил турында сөйләшү булачагын әйттереп була.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укучылар алдына Россиянең физик картасын урнаштырырга мөмкин. (Файдалы казылмалары белән булса тагын да яхшы, булмаса, аларны махсус урнаштыра алабыз.) Әлеге карта ярдәмендә дәреслек геройларының әңгәмәсе ачык аңлашыла. Нур репликасы картага игътибарны юнәлтә. Шул нигездә Россия дигән зур туган илебез турында сөйләшү үткәрәбез. Дәреслек геройларының әңгәмәсе аның табигый байлыклары, матурлыгы, табигате турында фикерләшүгә юл ача. Укытучы укучыларның белемнәренә таяна, өстәмә мәгълүматлар биреп туган җир, ватан һәм үзебезнең кече ватаныбыз Татарстан турында сөйли. Россия картасы Алмаз репли-

касы (40 нчы бит) нигезендә Татарстанныкы белән алыштырыла. Татарстан турындагы әңгәмәдән соң Әхмәт Рәшитовның «Кояшлы ил – бәхет иле» шигырен өйрәнүгә күчелә. Шигырь белән танышу сүзлек эше, сорауларга җавап бирү эзлеклелегендә дәвам итә. Шигырьдәге сурәтлелекне, Туган илне тасвирлау өчен кулланылган гыйбарәләрнең мәгънәсен ачыклауга вакытны кызганмыйча, укучыларның бу сорауларга үзләре аңлап җавап бирүләре яхшы.

Татар мәктәпләрендә Энҗе Мөэминованың «Туган телем» шигыре дә өйрәнелә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Туган илебез Россия һәм Татарстан турында өйрәнелгән шигырьдәге сүзләрне файдаланып сөйләү.

**VI. Өй эше бирү.**

Ә. Рәшитовның «Кояшлы ил – бәхет иле» шигырен сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Республикам минем – Татарстан

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – Туган илебезнең бай, көчле һәм искиткеч матур зур Россия икәнен аңлау. Туган ил, Ватан, туган җир белән горурлану. Аның турында күбрәк белергә теләк уяну.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру, таблица, схема рәвешендә бирелгән мәгълүматны аңлау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, чагыштырып нәтиҗә ясау.

*Предмет нәтиҗәләр* – Гомәр Бәшировның «Безнең Татарстан» әсәренең эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирә белү, мөстәкыйль рәвештә теманы һәм әсәрнең төп фикерен билгеләү.

**Материал**: Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part2/.

**Җиһазлау**: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик, Татарстанның физик картасы.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алда үтелгәннәргә нигезләнеп, Туган ил, туган җир турында әңгәмә корырга, укучыларның фикерләрен тыңлап гомумиләштерергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек геройлары әңгәмәсе ярдәмендә һәм дәреслекнең 51 нче битендәге Татарстан картасына карап, дәрестәге уку мәсьәләсе куела.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреслектәге Татарстан картасын өйрәнеп, укучылар республикабыз турында үз фикерләрен әйтәләр. Аның шартлы билгеләренә карап (картаның чикләре Татарстан флагын чагылдырганлыгы, районнар янәшәсендәге тамгаларның шул районның, җирлекнең үзенчәлеген күрсәтүе), бу якларның үзенчәлеген, халкының эшчәнлеген билгеләү. Картада күрсәтелмәгән нинди үзенчәлекле тамгалар өстәп булуы белән кызыксыну. Мәсәлән, Чистайда – сәгатьләр җитештерелү, Кукмарада киез итекләр һәм савыт-саба һ.б. балаларның картада күрсәтелмәгән нинди районнарны әйтә алулары белән дә кызыксынырга мөмкин.

Алга таба эш Гомәр Бәшировның «Безнең Татарстан» әсәрен уку, сүзлек белән эш, сорауларга җаваплар табу рәвешендә дәвам

итә. Текст белән эшләгәндә, аның теленең үзенчәлеген тоярга өйрәтү дә әһәмиятле. Мәсәлән, «бүреләр бар» дип әйтми, *юк түгел* ди. «Зур агымсулар ага» түгел, *агымсулар бизи,* «бик матур» түгел, *ни тора*. Пошилар, аюлар, бүреләр һәм төлкеләр дип кенә санап чыкмый, *учар мөгезле мәһабәт пошилар* һ.б. рәвешендә тел бизәкләре һәм тәэсирлелек, сурәтлелек арттырыла.

Шулай итеп, *антонимнар* төшенчәсен ачыклау һәм тексттан антонимнарны табу эше башкарыла: *урман – дала, болын – әрәмә, агым сулар – күлләр, салкын – эссе*. Шулай ук тексттан синоним сүзләрне дә табарга мөмкин.

Татар мәктәпләре өчен дәреслек геройларының Татарстаныбыз тарихы турында биргән өстәмә мәгълүматы ирекле әңгәмә өчен җирлек булып тора.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәрес темасын ныгыту өчен, кабат картага әйләнеп кайтырга кирәк. Гомәр Бәшировның «Безнең Татарстан» текстына һәм дәрестә алган мәгълүматларга нигезләнеп, укучы монологик сөйләм төзи. Аның өчен бу бирем авыррак булган очракта, ул укытучының сорауларына тулы җаваплар бирә ала. Текст буенча сорауларны укучылар бер-берсе өчен дә әзерләргә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Гомәр Бәшировның «Безнең Татарстан» әсәренең эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Үз илемнең баласы мин

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – Туган ил, Ватан, туган җир белән горурлану. Туган ил, туган җир белән кешенең бик тә ае-

рылгысыз икәнлеген аңлау. Ватаның, халкың алдындагы бурыч, җаваплылыкны аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру, гомумиләштерүләр ясау; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Равил Фәйзуллинның «Синеке – илнеке» һәм Ләбиб Леронның «Татар баласы» шигырьләренең эчтәлеген аңлау, аның нигезендә сорауларга җавап бирә белү.

**Материал**: Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part2/.

**Җиһазлау**: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

### I. Оештыру-мотивлаштыру.

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

### II. Актуальләштерү.

Алдагы дәрестә бирелгән өй эшенә нигезләнеп яки туган җир турындагы мәкальләр ярдәмендә яңа темага якынаерга мөмкин.

### III. Уку мәсьәләсен кую.

Дәреслек геройлары әңгәмәсенә кушылу ярдәм итә. Нурның: «Ә без Туган илнеке» дигән сүзләре белән хәл ителә. «Ә ни өчен Нур шулай дип әйтә, моны ничек аңларга?» дигән сорау куела.

### IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.

Равил Фәйзуллинның «Синеке – илнеке» шигыре белән танышуны шигырьнең исемен аңлап кабул итүдән башларга була. Моның белән укучылар нинди фикер аңлауларын, шигырьнең нәрсә турында икәнлеген фаразлап әйтәләр. Әлеге фикерне китапның 57 нче битендәге рәсем белән дә бәйләнешкә кертеп карарга

мөмкин. Анда балаларның мимикасы, хәрәкәтләре тирә-яктан канәгатьлек, күңел ләззәте кичерүләрен күрсәтеп тора. Фикерләрне гомумиләштереп, ил һәм анда яшәүчеләрнең байлыгы – һәммәсе дә уртак икән, дигән нәтиҗәгә киленә. Шигырь дә шул турыда булырга тиеш дип фаразлана.

Шигырьне укып, сүзлек белән танышкач, укучылар алдагы фаразларының дөреслеген тикшерә.

Шигырьнең беренче куплетында (6 юл) язылганча, Туган илдәге байлык анда яшәүчеләрнеке – синеке.

Икенче куплетның мәгънәсен ачыклауга күчәбез.

*Һәммә нәрсә синеке,*

*Ә син Туган җирнеке* дигән юллар синең, димәк, һәркемнең туган җирдән аерылгысызлыгын дәлилли. Синең һәр эшең газиз Туган илеңнеке дә. Синең сөенечләрең, уңышларың – ил шатлыгы. Әгәр кайгылар, көенечләр китерсәң, ил өчен дә оят, чөнки син – туган илнең улы.

Димәк, син һәр эшне ил алдындагы бурычыңны тоеп эшләргә тиеш, дигән нәтиҗәгә килерлек әңгәмә үткәрелә. Бу нәтиҗәгә килү өчен, дәреслектәге сораулар ярдәм итә ала. Иң элек шигырьнең асыл мәгънәсенә төшенеп, дәрес башында, уку мәсьәләсен куйганда туган сорауга җавап табарга, соңыннан ныгыту өлешендәге сорауларга җаваплар бирергә мөмкин.

Татар мәктәпләрендә Ләбиб Леронның «Татар баласы» шигыре дә өйрәнелә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Сорауларга җавап бирү һәм дәреслектәге мәкальләр белән эш рәвешендә үткәрелә ала.

**VI. Өй эше бирү.**

Равил Фәйзуллинның «Синеке – илнеке» шигырен сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Туган ил була бер генә (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – кеше һәм туган җирнең бәйләнешен, туган җиргә, туган телгә мәхәббәтнең олылыгын, туган илне, туган телне саклауның изге бурыч булуын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен кую, алган белемнәрне мөстәкыйль файдалана, тиз эшли алу, бәяләү; нәтиҗәләр формалаштыру, гомумиләштерү ясау; таблица, схема рәвешендә китерелгән мәгълүматны аңлау; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Туган илем, туган телем» бүлегендә өйрәнелгән әсәрләрнең исемен, аларны язган авторларны, әсәрләрнең эчтәлеген, андагы геройларны белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1 .

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укытучы Туган ил һәм туган тел турында матур шигырь юллары яки мәкальләр тәкъдим итә ала. Алар турында сөйләшү темага алып чыга. Алдагы дәресләрдә бу тема белән бәйле күп әсәрләр өйрәнүләре, бу дәреснең шул белемнәрне йомгаклау дәресе булуы ачыклана.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар тарафыннан дәреснең темасы билгеләнә. Кабатлау дәресендә нинди эш төрләре булачагы әйтелә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Дәреснең бу этабында укытучы биремнәрне үзе теләгән формада тәкъдим итә. Ике төркемгә бүлеп, төркемнәргә исем бирергә дә мөмкин. Әйтик, «Ватанпәрвәрләр» яки «Ил сөярләр» (патриотлар) һәм «Тел сөярләр».

Бу очракта ике төркем өчен аерым биремнәр әзерләнә. Төркемнәр бер-берсенә булыша (бер төркем җавап бирә алмаганда, икенчесе җавап бирә). Биремнәр эчендә укучыларның мәкаль һәм әйтемнәрне дә белүләрен истә тотып эшләргә мөмкин. Төп биремнәр дәреслектә үтелгән бүлекне кабатлауга нигезләнергә тиеш. Дәреслектә кабатлау өчен тәкъдим ителгән биремнәрне дә шул максатка хезмәт иттерү кирәк, алар игътибарсыз калмасын.

Төркемнәрдә дөрес җавап өчен «Ил сөярләр»гә – йөрәк, «Тел сөярләр»гә лалә чәчәге бирелә.

Алдагы этапка йомгак ясаганда, тактага Россия картасы эчендә Татарстанның чикләре билгеләнгән карта эленә. Укучылар Россия картасы чикләре буенча йөрәк рәсемен тезә, ә Татарстан картасы лалә чәчәкләре белән бизәлә. Һәр укучы, Туган ил яки туган тел турында матур теләк, фикерен әйтеп, йөрәк яки чәчәк тамгасын беркетсә бик яхшы. Туган илебезне, туган телебезне яратабыз һәм саклыйбыз, дигән нәтиҗә ясала. Нәтиҗәдән соң укытучы Татарстан гимны, «Туган тел» җырын бергәләп башкаруны тәкъдим итә ала яки дәресне матур шигырь юллары белән тәмамлый.

Аерым бүлекне тәмамлаганда, «Минем китапханәм»дә күрсәтелгән китапларга игътибар бирелә, алар укучыларга өстәмә уку өчен тәкъдим ителә.

**V. Өй эше бирү.**

Сыйныфтан тыш уку өчен бирелгән берәр әсәрне укырга тәкъдим итәргә.

**VI. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Язның тәүге ае – март

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – ел фасыллары табигатьтә тудырган үзгәрешләрне күзәтергә өйрәнү; безнең якларда яз башының үзенчәлеген тою, табигать матурлыгын күрә, кичерә белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; гомумиләштерү, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Әминә Бикчәнтәеваның «Март аенда» шигыренең эчтәлеген аңлау, аның буенча сорауларга җавап бирә белү, шигырьдәге тел-сурәтләү чараларын табу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part2/.

**Җиһазлау**: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучыларның тормыш тәҗрибәсенә таянып, ел фасылларын, аларга хас билгеләрне, һәр ел фасылы белән аерылгысыз булган бәйрәмнәрне искә төшерергә мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек геройларының әңгәмәсе уку мәсьәләсен куярга ярдәм итә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әминә Бикчәнтәеваның «Март аенда» шигыре белән танышу. Сүзлек белән эш һәм сорауларга җавап бирү төп өлешне алып тора.

Ул укучының язның беренче ае турындагы тормыш тәҗрибәсен әдәби текст белән бәйләргә булыша. Шигырьдә март аеның кышкы салкыннардан соң тәүге уяну, беренче чәчәкләр, кояш нурлары, карның суга әйләнүе – яз билгесе, яз төсе икәнен күрүләренә ирешү кирәк. Әмма март образындагы каршылыкны табу тагын да әһәмиятлерәк. Кыска һәм гади генә шигырьдә язның беренче аеның бөтен каршылыклы сыйфатлары ачыла. Әлеге каршылыклы образлылыкны ачарга 65 нче биттәге рәсем ярдәмгә килә. Иң элек рәсемнең шигырь эчтәлеген ни дәрәҗәдә ачуын, алар арасындагы тәңгәллекне табудан башларга була. Шигырьдә ул түбәндәгечә ачыла: *кар – асты су, кар астында – чәчәк, март яз китерә, әмма бураннары бар. Песи урамга чыга* (һәр нәрсәнең язга, иреккә омтылуы), *тик әле тәпиләре туңа* (март кояшы алдаучан).

Алга таба сорауларга җавап бирергә һәм «Март» дип аталган текст белән танышырга мөмкин. Бу ике текст арасындагы аерманы күрергә өйрәтү мөһим. Бу – берсе шигырь, икенчесе чәчмә формада булу гына түгел, укучыга мәгълүматны җиткерү алымындагы аерма да. Берсе – образлы тасвир, икенчесе – мәгълүмат бирү.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Шигырьдәге һәм тексттагы мәгълүматларга, тормыш тәҗрибәсенә нигезләнеп, язның беренче ае мартны тасвирлап, телдән рәсем ясау биремен тәкъдим итәргә була.

Әйбер, күренеш арасындагы охшашлыкка нигезләнгән образлылыкны аңларга песи, тал песие рәсеме һәм табышмак булыша. Ни өчен тал чәчәген тал песие дип атаулары турында уйланырга мөмкинлек бирү дә образ тудыруны аңларга ярдәм итә.

**VI. Өй эше бирү.**

Әминә Бикчәнтәеваның «Март аенда» шигырен сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Язгы авазлар

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигатьне ярату, аңа сакчыл караш кирәклеген аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, тамга-символик чараларны куллану; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп җиткерә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Гомәр Бәшировның «Язгы авазлар» хикәясенең эчтәлеген, темасын (нәрсә турында булуын) аңлау һәм әйтеп бирү, терәк схема нигезендә эчтәлеген сөйләү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1 .

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

### I. Оештыру-мотивлаштыру.

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

### II. Актуальләштерү.

Табигатьтә яз күренешен (сөңге бозлардан тамган тамчы, карны ерып аккан гөрләвек, бөреләре тулышкан агачта утырган сыерчык) сурәтләгән рәсемнәр ярдәмендә әңгәмә үткәрергә мөмкин.

### III. Уку мәсьәләсен кую.

Уку мәсьәләләсен куярга дәреслек геройларының әңгәмәсе ярдәмгә килер.

### IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.

Алмазның сүзен дәвам итеп:

– Чыннан да, нинди телдә сөйләшә икән соң яз? Тыңлап карыйк әле, – дип, тамчы тамган, гөрләвек аккан, кошлар сайраган, кыр казлары кычкырган тавышларны язмада укучыларга тыңлатырга мөмкин. Алга таба Гомәр Бәшировның «Язгы авазлар» хикәясе белән танышу, сүзлек белән эш оештырыла. Сорауларга җавап бирү эшенә керешкәнче, укучылар үзләре бер кат хикәяне укып чыкса яхшы. Аннары аерым өлешләрнең эчтәлеген үз сүзләре белән сөйләтеп карарга мөмкин. Шуннан соң сорауларга җаваплар алына.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучыларның бу дәрестә яз, язгы ташу, яз көне безнең якка кайтучы кошлар турында нинди яңалык белүләрен ачыкларга мөмкин. Дәреслекнең 69 нчы битендәге рәсем Гомәр Бәшировның «Язгы авазлар» хикәясенең кайсы өлешенә туры килүен билгеләргә, рәсемгә карап, шул өлешне сөйләргә кушарга да була. Ни өчен казларны санарга ярамаганлыгын аңлатып бирүләрен сорау да хикәяне хәтердә калдырырга ярдәм итәр.

**VI. Өй эше бирү.**

Үз күзәтүләреннән чыгып, үзләре яшәгән җирлектә язның ничек килүен тасвирлап сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмиятен билгелиләр.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Кар астыннан чыкты яз

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – күзәтүчәнлеккә ия булу, соклана, ярата белү, сагыну хисен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, тамгасимволик чараларны куллану; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп җиткерә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Нәҗип Мадьяровның «Кар астыннан чыкты яз», Фатих Кәримнең «Яз җитә» шигырьләренең эчтәлеген, темасын (нәрсә турында булуын) аңлау һәм әйтеп бирү; шигырьдәге хисне, аның сәбәбен билгеләү, шигырьдәге хисне үз хисләре белән чагыштыру.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1 .

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Гомәр Бәшировның алдагы дәрестә өйрәнелгән «Язгы авазлар» хикәясендәге боз китү күренешен хәтердә яңартып, дәреслек геройларының әле дә шул хакта сөйләшүләре искәртелә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек геройларының әңгәмәсе һәм аның дәвамы булган «Боз өстендә – учак» язмасы яңа темага күчәргә ярдәм итә. (Бу урында язгы боз өстенә керергә, су буенда ялгыз йөрергә ярамаганлыгын яхшылап аңлату да сорала.)

Укытучы сөйли: «Кар эреп, елгалар боздан арчылгач, язның җылы көннәре башлана. Шуңа яз кар астыннан чыккан кебек тоела да. Безнең бүгенге дәресебезнең исеме дә шундый булыр: «Кар

астыннан чыкты яз». Ник шулай аталганын аңларга Нәҗип Мадьяровның шул исемдәге шигыре ярдәм итәр».

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Нәҗип Мадьяровның «Кар астыннан чыкты яз» шигырен укып, сүзлек белән эш үткәрелә һәм сорауларга җаваплар алына, биремнәр үтәлә. Дәреслекнең 73, 74 нче битендәге рәсемне җентекләп карап, анда нәрсәләр барын санап чыгу сүзлек байлыгын арттыруга булышыр.

Татар мәктәбендә укучылар Фатих Кәримнең «Яз җитә» шигырен дә өйрәнәләр.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Өйрәнгән әсәрләрдә язның нинди сыйфатлары кабатланып тора?», «Яз синең күңелеңдә нинди хисләр уята?», «Ни өчен яз турында нурлы, шау-шулы, чәчәкле дип сөйлиләр?» кебек гомуми фикерләүгә корылган һәм аерым әсәргә бәйле сораулар белән белемнәрне ныгытып кую мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Яз керде өебезгә

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – язгы матурлыктан ямь таба белү; тышкы матурлык һәм күңел матурлыгын, киң күңелле булу, башкалар турында да кайгырта белү кирәклеген аңлый алу; кеше өчен күңел матурлыгының әһәмиятенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; гомумиләштерү, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Р. Миңнуллинның «Яз керде өебезгә» шигыренең эчтәлеген аңлау, әсәргә караган сорауларга җавап бирү, шигырь героена бәя бирә алу.

**Материал**: Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Мөхәрләмова Г.Н. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part2/.

**Җиһазлау**: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Яз һәм күңелдәге хисләр турында әңгәмә үткәрергә мөмкин. Һәр укучы яз фасылына үз мөнәсәбәтен белдереп, фикерен әйтә ала.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек геройларының репликалары белән танышу дәрестә уку мәсьәләсен куярга ярдәм итә. Бу урында Гөлназның «Шатлык уртаклашкан саен арта, кайгы – кими бара» дигән сүзләренә игътибар итеп, язгы матурлык һәм күңел матурлыгы турында сөйләшү булачагы ачыклана.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Роберт Миңнуллинның «Яз керде өебезгә» шигыре белән танышу, сүзлек белән эш һәм сорауларга җавап бирү. Сораулар шигырьнең төп фикерен ачарга ярдәм итә. «Шигырь нәрсә турында?» дигән сорауны шигырь юллары аша тирәнтен ачу кирәк.

Укучылар аның яз турында булуын әйтәчәкләр. «Тагын нәрсә турында?» дип сорау куела һәм җавап эзләүгә күчелә. Шигырьнең героен, ягъни вакыйганы хикәяләүчене табу, сөйләменә нигезләнеп, аның хисләрен билгеләү зарур. Беренче өлештә ул язның тәрәзәдән керүенә шатлана, икенче өлештә бу шатлыкны үзенеке генә итәргә тели, өченче өлештә яз җылысын (шатлыкны) башкалар да көткәнлеген һәм шатлыкны әйләнә-тирәдәгеләр белән дә уртаклашырга кирәклеген аңлый. «Шигырьнең герое нинди?» дигән сорауга җавап бирү аның темасын ачыклап бетерергә ярдәм итә: шигырь яз матурлыгы һәм күңел матурлыгы, башкалар турында кайгырта белү турында.

2 нче сорау шигырьнең авторы турында киңрәк сөйләшү мөмкинлеге бирә. Укучылар инде Роберт Миңнуллин әсәрләре белән таныш. Аларны искә төшереп үтәргә дә була.

Алга таба барлык сорауларга да җавап биреп, шигырьнең эчтәлеген, андагы образлылыкны, рифмалашу үзенчәлекләрен ачыклау кирәк.

Дәреслек геройларының әңгәмәсе май аендагы бәйрәмнәр турында сөйләшүгә алып чыга.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Язгы матурлыкның тормышка нинди ямь өстәве, күңел матурлыгының шигырь героенда ничек чагылуы турында сөйләшү үткәрергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Роберт Миңнуллинның «Яз керде өебезгә» шигырен сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә яки шигырьнең героен тасвирлап сөйләргә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема:** Яз шатлыгы (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – язның табигать һәм кешеләр тормышына алып килгән үзгәрешләрен аңлау, табигать сулышын тоя, соклана һәм ярата белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; нәтиҗә чыгару, гомумиләштерү, тамга-символик чараларны куллану; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп җиткерә белү, тәкъдим ителгән үрнәкләргә таянып, күмәк проект биремнәрен үтәү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Яз керде өебезгә» бүлегендә өйрәнелгән әсәрләрнең исемен, аларны язган авторларны, әсәрләрнең эчтәлеген, андагы геройларны белү, образларны тану.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1 .

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Табышмак, шигырь, җыр, рәсем файдаланырга мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучыларга таныш шигырь юлларын таркатып биреп, аны берләштерергә яки рәсемне аерым пазл рәвешендә тәкъдим итеп җыйдырырга һәм дәреснең темасын ачарга була.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Кабатлау өчен бу бүлектә үтелгән темалардан сораулык әзерләнә.

Сорау бирү алымын экран ярдәмендә мавыктыргыч итеп эшләргә мөмкин. Елга буйлап агып баручы боз мендәрчеге башка бозларга бәрелеп туктый, димәк, аны кузгатып җибәрү кирәк була. Моның өчен язгы тамчы боз мендәрчеге өстенә тама, анда сорау ачыла, укучылар җавап бирүгә, боз сәяхәтен дәвам итә. Дөрес җаваптан соң елга ярында умырзая чәчәге рәсеме чыгарыла, җавап биргән укучыга да чәчәк бирелә. Эшнең ахырында экранда матур чәчәкләр белән капланган үзәннән агып ятучы елга сурәте кала.

Алдагы этапка нәтиҗә ясала. Яз матурлыгы һәм укучыларның үз белемнәре белән, бозны эретеп, яз китерүләрен чагыштыру, белемнең тормышны матурлавын искәртү кирәк.

Татар мәктәпләрендә Энҗе Мөэминованың «Май» шигыре дә өйрәнелә.

Аерым бүлекне тәмамлаганда, «Минем китапханәм»дә күрсәтелгән китапларга игътибар бирелә, алар укучыларга өстәмә уку өчен тәкъдим ителә.

**V. Өй эше бирү.**

«Яз килә» темасына проект эше эшләргә кушыла. Аны үтәү тәртибе аңлатыла.

**VI. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема:** Малайлар сөйләшә

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – киләчәк турында хыяллана белү, тормышта максатлар куярга өйрәнү, Кеше булуның мәгънәсен: кешелеклелек, шәфкатьлелек һ.б сыйфатларның әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; гомумиләштерү, нәтиҗә чыга-

ру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Роберт Миңнуллинның «Малайлар сөйләшә» шигыренең эчтәлеген аңлау, аның нигезендә сорауларга җавап бирү, шигырьнең темасын һәм төп фикерен билгеләү.

**Материал**: Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part2/.

**Җиһазлау**: проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучыларның нинди һөнәрләр белән танышлыклары турында кызыксынып, сөйләшү үткәрергә була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек геройларының әңгәмәсе белән танышу уку мәсьәләсен куярга ярдәм итәчәк.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Роберт Миңнуллинның «Малайлар сөйләшә» шигырен уку, сүзлек белән эш һәм сорауларга җавап бирү эзлеклелегендә эшләү шигырьнең төп фикерен ача. Дәрестә шигырь белән танышкач, укучыларны ирекле әңгәмәгә алып чыгарга мөмкинлек туа. «Үскәч, кем нинди һөнәр сайларга тели? Ни өчен?» Укучылар атамаган һөнәрләрне дә искә төшерергә кирәк. Аларның тормыштагы әһәмиятенә тукталу яхшы. Алга таба шигырьдәге һөнәрләрне ачыклый башларга була. Аларга бәя бирә барабыз. Һөнәр һәм һөнәр булмаганнарын (әти, дәү әти h.б) аерып чыгаралар. Начальник вазифасына ачыклык кертелә – ул «Волга»да гына

йөрүчеме? Һөнәрне сайлаганда, аның нинди вазифа башкаруын яхшы белү кирәклеге дә искәртелә. Шигырьдәге сабыйларча эчкерсезлекне күрә алсалар, тагын да яхшы булыр.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Сабантуй бүләге» дәреснең темасын ныгытырга ярдәм итә. Укучылар белән КЕШЕ булу, кешелеклелек турында әңгәмә үткәрергә, аны тормыштан мисаллар белән ныгытырга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Роберт Миңнуллинның «Малайлар сөйләшә» шигырен сәнгатьле итеп укырга яки «Мин үскәч кем булырга телим?» дигән темага кечкенә сочинение язарга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кызык та, кызганыч та

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – үзеңә тиешле эшне башкаларга йөкләмәскә, һәр нәрсәне вакытында үтәргә, үзеңдә матур сыйфатлар тәрбияләргә тиешлеген аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилләп җиткерә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Шәүкәт Галиевнең «Онытылган...», Заһирә Гомәрованың «Кайда булсын – кесәмдә» шигырьләренең эчтәлеген, темасын (нәрсә турында булуын) аңлау һәм әйтеп бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. /http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1 .

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру

**II. Актуальләштерү.**

Укытучы укучылардан дуслары белән аралашулары, нәрсәләр турында сөйләшүләре, ничек (телефоннанмы, күрешепме) аралашулары турында сораша ала.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек геройларының мәктәптәге төрле кызык хәлләр турында да сөйләшүләрен билгеләп, аларның әңгәмәсенә кушылып кителә. Шуның нигезендә бу дәреснең темасы ачыклана.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Шәүкәт Галиевнең «Онытылган...» һәм татар мәктәпләре өчен бирелгән Заһирә Гомәрованың «Кайда булсын – кесәмдә» шигырьләре белән танышуны укытучы үзе теләгән эзлеклелектә оештыра. Шигырьләрне өйрәнүнең тәрбия бирү, әдәпкә, тәртипкә өйрәтү белән кушылып китүе бик кирәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреснең бу этабы укыган әсәрләрне хәтердә калдыруны ныгытуга һәм тәрбияви фикерләрнең үзләштерелүенә, күнекмә буларак формалашуга этәрергә тиеш.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема**: Елмаеп та, көлеп тә (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – кеше холкындагы кимчелекле сыйфатларны күрә белү, аларны үзеңдә булдырмаска кирәклеген аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – алган белемнәрне мөстәкыйль файдалана, тиз эшли алу, бәяләү; нәтиҗәләр формалаштыру, гомумиләштерү ясау, тамга-символик чараларны куллану; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Көлке көлә килә» бүлегендә өйрәнелгән әсәрләрнең исемен, аларны язган авторларны, әсәрләрнең эчтәлеген, андагы геройларны, юмористик әсәрләрнең үзенчәлеген белү. Резеда Вәлиеваның «Бу сыйныфка ни булган?» шигыренең эчтәлеген, темасын (нәрсә турында булуын) аңлау һәм әйтеп бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. /http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1 .

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру

**II. Актуальләштерү.**

Укытучы кечкенә гыйбрәтле хикәя тәкъдим итә ала.

Бер кеше үзенең әдәпле һәм тәрбияле булуы, күркәм холкы белән һәр җирдә үрнәк булган, башкаларда соклану уяткан. Бервакыт аңа сорау биргәннәр:

– Син бу кадәр күркәмлекне үзеңдә ничек тәрбияли алдың?

Ә ул җавабы белән башкаларны гаҗәпкә калдырган:

– Әдәпсез һәм тәрбиясезләрдән өйрәндем, – дигән.

– Ничек алай? – дигәннәр аңа.

– Аларның кимчелекләрен күрдем дә үземдә бу сыйфатларны булдырмаска тырыштым, – дигән ул.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укытучы сөйли:

– Укучылар, без бүген кешедәге матур һәм килешсез сыйфатлар турында сөйләшүебезне йомгаклап нәтиҗә ясарбыз. Дәресебезне «Елмаеп та, көлеп тә» дип атыйк әле.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Укытучы дәвам итә:

– Без һәрвакыт шатлыктан, канәгатьлек хисеннән генә елмаймыйбыз бит. Килешсез, хаталы гамәл күргәндә дә елмаеп куябыз. Без алдагы дәресләрдә укыган әсәрләрдә дә шундый хәлләр очрады бит. Ә сез аларны дөрес аңладыгызмы икән? Дәресебезнең кунагы Нурның шуны беләсе килә (аны экранга чыгару яхшы). Шуның өчен ул биремнәр әзерләп килгән. Һәр җавап өчен Нур үзенең елмаюын бүләк итәр. Дөрес җавап өчен – канәгатьлек билгесе чагылган елмаю, җавап дөрес булмаса, канәгатьсезлек белдереп елмаю («елмаю» тамгалары экранга чыга). Укучылар өчен «канәгать елмаю» тамгасы гына кәгазьдә эшләнә. Ул дөрес җавап биргән укучыга гына эләгә.

Укытучы үзе әзерләгән биремнәр белән бу бүлекне гомумиләштерү эшен башкара. Биремнәрне Алмаз янәшәсенә экранга чыгарырга һәм җаваптан соң тиешле «елмаю» белән бәяләргә һәм дөрес җавап бирүчегә «елмаю» тамгасы тапшырырга кирәк. Биремнәр буларак, төрле ситуатив сораулар бирергә дә мөмкин. Бу темада үтелгән әсәрләр буенча дәреслектәге сорау һәм биремнәрне дә куллану кирәк.

Дәреснең алдагы өлешенә нәтиҗә ясала. Начардан үрнәк алмаска, аны кабатларга кызыкмаска, киресенчә, гыйбрәт алып нәтиҗә ясарга, үзеңдә күркәм сыйфатлар тупларга омтылырга, КЕШЕ булу өчен нинди булырга кирәклеге турында сөйләшелә.

Гомуми нәтиҗәгә кадәр Резеда Вәлиеваның «Бу класска ни булган?» шигыре өйрәнелә.

Аерым бүлекне тәмамлаганда, «Минем китапханәм»дә күрсәтелгән китапларга игътибар бирелә, алар укучыларга өстәмә уку өчен тәкъдим ителә.

**V. Өй эше бирү.**

Сыйныфтан тыш уку өчен тематик яктан туры килә торган берәр әсәрне укырга.

**VII. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала

**Тема**: Исәнме, җәй!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигатьтә ел фасыллары алышынгандагы үзгәрешләрне, аның кеше күңеленә тәэсирен аңлау; сагыну, соклану, шатлык хисләрен кичерә, тоя белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру, тамга-символик чараларны куллану; әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Резеда Вәлиеваның «Исәнме, җәй!», Шәриф Камалның «Җәйге иртә» әсәрләренең эчтәлеген, темасын (нәрсә турында булуын) аңлау һәм әйтеп бирү; шигырьдәге хисне табу, хиснең сәбәбен билгеләү, ул хисне үз хисләре белән чагыштыру.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1 .

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру

**II. Актуальләштерү.**

Укытучы дәресне шигырь, табышмак белән башлап җибәрә ала.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укытучы:

– Ә безнең дусларыбыз нәрсә турында сөйләшә икән? Әйдәгез, аларны да тыңлап карыйк әле, – дип, дәреслек геройларының әңгәмәсенә күчеш ясый. Дәреслек геройларының диалогы укучыларга дәреснең темасын билгеләргә ярдәм итә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Резеда Вәлиеваның «Исәнме, җәй!» шигырен өйрәнүне укытучы үзе теләгән эзлеклелектә оештыра. Шигырьдәге күтәренке рухны, шатлык хисен, хиснең сәбәбен укучылар үзләре таба алырга тиеш. Татар мәктәпләрендә шигырьдәге чагыштыруны (күбәләктәй Зөләйха) таптыру да уңышлы булыр. Шигырьнең эчтәлеген андагы сүзләрне кулланып та сөйләп карасыннар.

Татар мәктәпләрендә әңгәмәне укучыларның җәй турында үз фикерләрен тыңлау белән дәвам итә алабыз. Аннары Алмаз һәм Нур арасындагы сөйләшү аша Шәриф Камалның «Җәйге иртә» хикәясен укуга күчәбез. Бу эшне укытучы үзе дөрес дип тапкан эзлеклелектә оештыра. Хикәядәге сынландыруга да (кояш исәнләште), сурәтләүнең матурлыгына, образлылыкка да игътибар итәбез.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

«Җәй нинди билгеләре белән башка ел фасылларыннан аерыла?»

«Ни өчен кешеләр җәйне сагынып көтә?»

«Резеда Вәлиеваның «Исәнме, җәй!» шигырендә малайлар, кызлар җәй килгәнгә ни сәбәпле шатлана?»

«Җәйне тасвирлаганда нинди образлар кулланылган (*кояш, гөлләр, чәчәкләр*...)?» һ.б сораулар укучыларга бу дәрестә белгәннәрне ныгытырга ярдәм итә ала.

**VI. Өй эше бирү.**

Резеда Вәлиеваның «Исәнме, җәй!» шигырен ятларга.

**VII. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема**: Җәй көтә безне

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – табигатьне ярату, аңа соклану хисенә ия булу, аңа сак караш кирәклеген аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру, тамга-символик чараларны куллану, төрле текстларны чагыштыру, текстларны чагыштыру өчен нигезләр табу, нәтиҗәләр формалаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Ләбиб Леронның «Җәй көтә безне», Рахмай Хисмәтуллинның «Июль аланы» шигырьләренең эчтәлеген, темасын (нәрсә турында булуын) аңлау һәм әйтеп бирү, шигырьдәге хисне билгели алу, ул хисне үз хисләре белән чагыштыру.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1 .

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Бу этапта дәреслек герое Алмазның табышмагы ярдәм итәр.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Сара белән Гөлназ әңгәмәсе темага алып чыга.

– Укулар бетүгә, безне җәй көтә, – ди алар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреснең темасын ачыклаганнан соң, укучылар белән җәй турында әңгәмә корырга мөмкин. Алар узган җәйдән калган истәлекләр, быел җәйне ни өчен көтүләре, алга планнары белән уртаклашырлар. Бу әңгәмәне дәреслекнең 108 нче битендәге рәсем нигезендә сөйләшү белән дәвам итәргә була.

Ләбиб Леронның «Җәй көтә безне» шигырен укуга күчкәндә, шигырьнең исеменә кабат игътибар иттерү кирәк. «Без җәйне көтәбез» һәм «Җәй көтә безне» дигән исемне чагыштырып карап, икенчесенең тәэсирлелеген, үзенә дәшеп торуын аңлый алсыннар иде. Бу исем белән үк шагыйрь күңелне кузгата, чыннан да, чакырып, көтеп торган җиргә барасы килү теләге уяна.

Алга таба Ләбиб Леронның «Җәй көтә безне» шигырен укуны укытучы үзе теләгән формада оештыра. 108–109 нче битләрдәге Дәреслек биргән өстәмә мәгълүматка игътибар юнәлтергә һәм аңлатып китәргә кирәк.

Татар мәктәпләрендә укучылар өчен Сараның альбомы Рахмай Хисмәтуллинның «Июль аланы» шигырен өйрәнүгә алып чыга. Шигырьне уку һәм альбом белән танышу укучыларда табигатькә карата кызыксыну уята, аның матурлыгына сокланырга һәм файдалы ягын күрергә ярдәм итә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу этапта җәй турында сөйләшкәннәрне кабат искә төшереп, «Сабантуй бүләге»ндәге мәкаль мәгънәсенә нигезләнеп нәтиҗә

ясыйбыз. Җәй ял һәм уеннар өчен генә түгел, файдалы хезмәт турында да онытмаска кирәк.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән дәрескә нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

**Тема**: Яхшы бел үткәннәрне (гомумиләштереп кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – ярату, соклану, сагыну хисләренә ия булу, матурлыкны саклау кирәклеген аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – алган белемнәрне мөстәкыйль файдалана, тиз эшли алу, бәяләү; нәтиҗәләр формалаштыру, гомумиләштерү ясау, тамга-символик чараларны куллану; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – бу уку елында өйрәнелгән әсәрләрнең исемен, аларны язган авторларны, әсәрләрнең эчтәлеген, андагы геройларны, теоретик төшенчәләрне белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 2 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан, 2023. / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/#p=-1 .

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Бу этапта дәреслек геройларының әңгәмәсенә нигезләнү мөмкин.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Нур репликасы бу дәреснең темасын билгели: ул ел дәвамында үткәннәрне кабатлау дәресе булачак.

Әдип Маликовның «Мәктәп баласына» шигырен укып, укытучы теманы укучыларга җиткерә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Шигырь эчтәлегенә нигезләнеп, белемнәрне хәтердә саклауның әһәмияте, өлкәннәрнең дә, хәтта табигатьнең дә балаларның белемле булуына шатланулары турында әйтеп үтәргә мөмкин.

Кабатлау дәресенең форматын укытучы үзе хәл итә. Куллану өчен дәреслектәге биремне нигез итеп алырга була.

Белемнәрне тикшерү өлешеннән соң Нур алдагы дәрестә алып килергә вәгъдә биргән альбомы белән таныштыра. Әлеге альбом укучыларга җәйге ялларында күзәтүчән булырга чакыра, бәлки, бу урыннарны күрәсе килү теләге дә уяныр.

Дәрес материалына нигезләнеп нәтиҗә ясала. Укучылар үзләрен кызыксындырган нәрсәләр турында сөйли һәм сораша алалар.

Дәресне тәмамлаганда, «Минем китапханәм»дә күрсәтелгән китапларга игътибар бирелә, бу китаплар укучыларга өстәмә уку өчен тәкъдим ителә. Укытучы каникулга өй эше бирә. Ул һәр укучының мөмкинлегеннән чыгып эшләнә.

**VII. Рефлексия.**

Әлеге этапта укучылар белән нәтиҗә ясала. Дәрестә әйтелгән төп фикерне яңадан күңелдә барлап, аның әһәмияте билгеләнә.

Бәяләү, үзбәя ясала.

Матур теләкләр белән яңа уку елына кадәр саубуллашабыз.

Учебное издание

**Абдуллина** Дилария Маратовна
**Мухарлямова** Гульназ Нурфатовна

ЛИТЕРАТУРНОЕ ЧТЕНИЕ

**2 класс**

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
начального общего образования, работающих
с учащимися, изучающими татарский язык как родной

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

**Абдуллина** Диләрия Маратовна
**Мөхәрләмова** Гөлназ Нурфатовна

ӘДӘБИ УКУ

**2 нче сыйныф**

Методик әсбап
Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында
татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән
эшләүче укытучылар өчен

Мөхәррире *Л.Г. Шәрифуллина*
Рәссамы *Д.Л. Нәүрузова*
Компьютерда биткә салучысы *Э.Ф. Нурмөхәммәтова*

Подписано в печать с оригинал-макета 10.04.2023
Формат 60 x 84 1/16. Бумага офсетная.

